**ЯҢА КЕШЕЛӘР**

Драма өч пәрдәдә

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

КАТНАШУЧЫЛАР

Хәйри – авыл бае, таза, нык, гайрәтле; яше 55 ләрдә.

Зөһрә – Хәйринең яшь хатыны; чибәр, булдыклы, бераз зәһәрле, куштан; яше 30 ларда.

Фәтхия – Хәйринең карт хатыны; юаш, йомшак, елаучан табигатьле.

Батырхан – таза, нык, гайрәтле, үткен табигатьле; бик аз укыган авыл ярлыларыннан, 30 яшьләрдә.

Бибизәйния – Батырханның хатыны, Хәйри байның карт хатынының кызы, сөйкемле, уйчан табигатьле; беренче, икенче пәрдәләрдә авыр уйлаудан йөзе саргая төшкән. Күзләрендә, тавышында бераз хыялый төс бар.

Вәли – Хәйринең карт хатынының улы; яше 30 ларда.

Камәр – яшь, матур, үткен мөгаллимә. Шат, моң, ачык табигатьле.

Шәйбәк бабай – ярлы авыл карты; зур ак сакаллы, киң ачык маңгайлы, изге, суфый, диндар кеше; яше 70ләрдә.

Тимеркәй – Хәйри байның карт хатынының үлгән кызының улы. Яшьтән ятим калып, Хәйридә ялчы урынында эшләп үскән; үткен, тере йөрәкле егет; яше 20ләрдә.

Насыйб }

Ярми } авыл егетләре, ярлы крестьяннардан.

Тимерче Гайнетдинов.

Шәнгәрәй – авыл советы рәисе, ярлы крестьян.

Әптерәш – Хәйри байда егерме еллап торган карт ялчы. Акрын кузгала, сабыр сөйли.

Иванов } Батырхан белән килгән кызылармеецлар.

Шакиров }

Габдулла – тәрәзәдән икмәк, сөт сорап алучы кызылармеец; Әптерәшнең якын кардәше.

[1+]Пәрдә ачылганда җәйге кич. Хәйри байның яңа өе. Өй авылча бай, чибәр җыештырылган.

Пәрдә ачылыр алдыннан гармун белән «Уел» көе[2+] уйналган тавыш килә. Кемдер матур, калын аваз белән аңа кушылып җырлый. Җыр бетмәс борын туп-мылтык аткан тавыш килә.

Бибизәйния *(аптыраган төс белән килеп керә. Урам як тәрәзәсен ачыйм дигәндә туп-мылтык тавышына кинәт сискәнеп китә. Үзалдына).*

Ходаем, бетерәләрме икәнни? Җиде ел көттем бит! Тагы миңа кермиче китәрме икәнни? *(*Аптырашлы йөреше белән чыгып китә.)*

Х ә й р и бай (*Бибизәйния чыгуга, тирләп-пешеп, бик артык кирәкле бер эшкә ашыккан төс белән килеп керә. Аның аягында читек, өстендә камзул. Нәрсәдәндер шикләнгән кеше кебек, як-ягына күз ата, мич артына аеруча дикъкать белән карый да бераз каушаулы, ашыгыч, каты тавыш белән кычкырына башлый*). Зөһрә! Зөһрә!.. Вәли! Сез кайда? (*Тагы бер сәгатькә карый, бер ишеккә карый; тәрәзәгә ашыгып барып, күз ташлый.*) Чәнчелгерләре! Сиңа кирәк чакта берсе дә юк! (*Ишекне ачып, башын тыга да, тагын катырак тавыш белән*). Зөһрә! Вәли!..

Ф ә т х и я к а р ч ы к *(куркып, каушап килеп керә. Аягында оек, иске күн ката. Өстендә аксыл күлмәк).* Атасы, ни булды? Әллә берәр хәл бармы?

Х ә й р и *(йөзен, кашын җыерып, ачуланып).* Юк, юк, бернәрсә дә юк! Миңа син кирәкми! Бар, чыгып кит! Зөһрә белән Вәлигә әйт, тиз генә минем яныма керсеннәр, аларда минем йомышым бар.

Ф ә т х и я *(рәнҗеп, гарьләнгән тавыш белән).* Ходаем, бу нинди эш инде бу? Мин синең катыньң түгелмени? Аларга әйтергә яраган йомышны нигә миннән яшерәсең?

Х ә й р и . Бар, бар, чык, синең белән тиргәшеп торырга вакытым юк... *(Төрткәләп куа башлый; Фәтхия ишеккә якынайгач, бераз сабыр тавыш белән.)* Карчык, син Бибизәйнияне яхшы кара... Ул бичара бу көннәрдә тагын бик артык хәсрәтләнә башлаган... Аннан соң теге шәйтан баласы Тимеркәйгә әйт: йокларга ятарга кушты диген! Ул дуңгыз бу арада бик күпне күрә башлаган... Ишеттеңме?

Ф ә т х и я *(сукранган тавыш белән).* Ярар. *(Чыгып китә.)*

В ә л и *(ашыгып килеп керә. Башында күк эшләпә, аягында итек, өстендә тужурка[1], чалбар; бер кулында кыршаулы капчык, өс-башы онга буялган).* Әткәй, ни бар? Безнекеләр килеп җитәләр диме әллә?

Х ә й р и *(шелтә белән).* Кайда йөрисең син шундый кирәк чакта?

В ә л и *(капчыгын күрсәтә).* Мин келәттә он үлчәп йөри идем әле: хакы яхшы, яңа ашлык өлгергәнче сатып калырга кирәк...

З ө һ р ә *(ашыгып килеп керә. Өстендә оборкалы күлмәк, башында алсу сарпинка яулык[2], муенында тәңкәләр, гәрәбәләр[3], кулында беләзекләр, артка үреп төшерелгән озын чәч толымнары очында зур көмеш чулпылар. Ул*

---

* 1921 елгы басмада: *Авыр, уйлы, аптырашлы йөреше белән чыгып китә.*

1 *Тужурка* – ике капламалы җиңел куртка.

2 *Сарпинка яулык* – буй-буй яки шакмаклы юка киҗе-мамык тукымадан тегелгән яулык.

3 *Гәрәбәләр* – саф нарат сагызы аерым шартларда гасырлар буена ятудан барлыкка килгән сары яки кызгылт сары төстәге үтә күренмәле асылташлар.

*кулындагы лампаны мич буена куя да иренең янына ук килә).* Атасы, син мине дә чакырдыңмы?

Хәйри. Чакырдым, чакырдым, икегезне дә чакырдым. *(Шелтә белән).* Дөнья кайнарга тора, шундый вакытта сез әллә кайда җыен юк-бар эш артыннан йөрисез!

Зәһрә, Вәли *(икесе берьюлы).* Ни бар? Ни бар?

Хәйри *(бераз тынычлана, изүен чишеп, җилсендерә, маңгай тирләрен сөртә, тәрәзәгә карап ала, яңа кертелгән зур лампаны бераз баса да Вәли белән Зөһрәне идән уртасынарак китерә).* Бар инде, бар, зур эшләр бар. Без хәзер генә Митри Степанычта булдык... *(Тавышы акрыная төшә, тәһдид белән[1]).* Бу бик яшерен сер. Кешегә-карага чыгармагыз, башларыгызны өзәрмен, ишетәмсез?

Зөһрә *(үпкәләп).* Ул нинди сүзең тагы? Әллә мин Саескан Фатимасымы, өйдәге серне урамга чыгып сөйләргә?

Хәйри. Ярар, ярар, үпкәләп барма. *(Икесен дә янына ук тартып.)* Митри Степаныч бит бер атнадан бирле, большевиклардан качып, байлар очында, Әтәч Садыйкта ята. Анда Аксак бояр, Кәҗә Якуп, Карун Гали, Тукран Хажи, тагы әллә кемнәр бар иде. Без анда озак киңәштек...-

Зөһрә *(бер каушап, бер шатланып).* Соң? Соң? Әллә безнекеләр килеп җитәләр диме?

Хәйри. Җитәләр генә түгел, җиткәннәр инде! *(Шатланып, кулларын уып.)* Теге дуңгызларны бетерәләр, ди. Безгә тагы элеккечә тормыш кайта, ди. Бүген караңгы төшкәч кенә, Кәҗә Якупның Намаҗаны каладан кайтты, ул әйтә, безнең эшләр майлаган арба кебек бара, ди. Теге кызыл шайтаннар яшеннән качкан кебек тыр-тыр качалар, ди. Красный гвардиннар чехка каршы сугышмый, ди... Моңарчы сез безне алдап йөрткәнсез икән дип, *(кулы белән күрсәтә)* большевикларның үзләрен штыкка күтәрәләр, ди.

Урамнан тавыш. Хәйри абзый өйдәме?

Хәйри *(кинәт куркына, Вәлигә акрын гына тавыш белән).* Бар, урамга чык, кем бар икән? Кем генә булса да, әткәй өйдә юк, диең! Ул китмичә кермә!

Вәли. Саескан Гәрәй малайларыдыр, тавышы шуңа ошый. *(Ашыгып чыгып китә.)*

Әптерәш *(акрын, салмак атлап килеп керә. Кулында йөгәннәр, нукталар; өстендә бик начар, иске, тар гына якалы чикмән, башында ертылгалап беткән мескен бүрек; чәче агарган, ияк очында җилбердәп торган сирәк сакалына да чал кергән; бер байга, бер Зөһрәгә карап,*

---

[1] *Тәһдид белән* – янап.

*карлыкканрак тавыш белән).* Ярый, өйдә икәнсең әле. Сиңа шуны әйтим дигән идем...

Хәйри. Карт, син бит карчыгыма кайтып киләм, дидең... Нигә һаман китмисең? Бар, бар, чык! Монда безнең эш бар!

Әптерәш. Хәйри туган, эш дигәнең гүргә кермичә бетмәс инде ул... Менә мин сиңа егерме ел эшләдем... Һаман да бетерә алганым юк синең эшеңне... Үзең кушкач, карчыгымның хәлен белеп кайтыйм дип уйлаган идем... Түбен очка барып җиткәч, анда шау киләләр... Батырхан кайта икән, Батырхан кайта икән диешәләр... Шуны ишеттем дә кире борылдым. Тукта, мин әйтәм, Батырхан баламның китүенә җиде ел булды, дим... Ул, дим, йә ашыгып китә башлар... Ул кайтканчы китмим әле, дим... Күрәсем бик килде аны.

Хәйри *(кызып, каһәрләп).* Их, карт, карт! Егерме ел сине өйрәттем. Һаман акылга утырта алмадым... Сиңа нинди Батырхан кирәк?! Ул каторжникны, ул разбойникны әллә кайчан асканнар инде!.. Бар, бар, акылдан шашып йөрмә, мин җибәргәндә карчыгыңа кайтып кил...

Зөһрә. Бабай, син җибәргәннең кадерен бел, мондый кызу эш вакытында кунакка җибәргәнгә рәхмәт әйт. Әнә, Гәрәйләрнең ялчылары елга бер мәртәбә дә өенә кайта алмый...

Әптерәш *(акрын кузгала, кулын селкә).* Йә, исән булсак, тагын бервакыт табып, карчыгыма барырмын әле. Мин Батырханны көтәм. Ул кайтмыйчы китмим... *(Чыга).*

Хәйри. Әллә ни булды бу халыкка!.. Егерме ел бер сүз каршы әйтми эшләгән ялчы хәзер синең белән карулаша.

Зөһрә. Бары да шул кызыл иблисләр шомлыгы... *(Ишектән килеп кергән Вәлигә.)* Ни бар, кем килгән?

Вәли. Теге Саескан Гәрәйнең малае килгән. Арба сорый. Тегермәнгә барып кайта идек, ди.

Хәйри. Ни дидең?

Вәли. Нәрсә әйтим, юк, дидем... Кызыллар алып бетерде, дидем.

Зөһрә. Ә алаймы? Арба кирәк булгач исенә төшкән икән! Бөтен авылны парлап ашка җыйганда безне оныта, берәр кирәге булса, тагы килеп җитә! Саескан дисәң Саескан шул!

Хәйри *(шелтә белән).* Йә, катын, син ташла юк-бар үпкәләреңне; хәзер андый вакыт түгел... *(Ишекне барып нык яба, тәрәзәгә күз сала.)* Фу, каһәр төшкерләре, сүземне оныттырып бетерделәр. Ие... Ие, шулай, ди. Хәзер сәвиткә каршы бөтен дөнья күтәрелгән, ди. *(Кулы белән киң рәвештә уратып күрсәтә.)* Мәскәү, Казан бездә, ди. Теге ата большевик Ленин[3+] үзе дә безнекеләргә эләккән, ди... Сабый бала кебек өзелеп-өзелеп елый имеш, ди...

Еракта туп тавышы ишетелә; куркынып китәләр.

Вәли, Зөһрә *(икесе бергә шатланып).* Аны ни эшләткәннәр ди, асканнар диме?

Хәйри. Юк, ди, аңа тимәгәннәр, ди, әле... Башкаларның һәммәсен аякларыннан *(кулы белән югары күрсәтә)* түшәмгә асалар, ди, кайда тотсаң шунда асарга закон чыга, ди... *(Нидер хәтерләгән кебек, башын тота да, ашыгып, ишек төбендә чөйгә эленеп торган бишмәтенең кесәсеннән бер кәгазь алып килә.)* Котым очты, югалтканмын дип торам... *(Вәлигә.)* Менә моны Тукран малае Сәфәргә хәзер үк илтеп бирерсең. Бик кирәкле кәгазь, югалта күрмә...

Вәли *(кәгазьне ачып, лампага якынрак килә, кәгазьне карый).* Бу нәрсә турысында икән?

Хәйри. Аны теге... кем соң үзе... бар бит шунда, собраниеләрдә бик күп сөйләүче... *(Башын кашып).* Ә, белдем... белдем... теге Гомәр Гаязов төрле җирләргә яшерен тараттырган, ди... Монда мөселманнан азган большевикларның исемнәре, ди. Калада рәт беткәч, бу явызлар халыкны котыртырга дип авылларга таралганнар, ди. Аларны кайда күрсәң шунда үтерергә, ди.

Вәли *(кәгазьгә бик дикъкать белән күз йөртә).* Монда бездәге этләрнең исемнәре юк ахры?..

Зөһрә *(хәкарәт һәм ачу белән Вәлигә күз ташлап, иренен турсайта).* Таптың сүз! Бу көчекләрен калада телгә алып торалар ди сиңа!

Хәйри, Йә, эләгешеп бармагыз әле юкка! *(Вәлигә).* Шулайдыр, шулайдыр, безнекеләр кермәгәндер, ул кәгазь зуррак шайтаннар хакындадыр... Мондагы вак-төякләрне, Алла кушса, без үзебез дә бетерә алырбыз...

Зөһрә *(куштанланып, иренә сыена төшеп).* Әй син, кара әле, чех-чех дип көн-төн сөйлиләр, безгә дә шулар киләме икән? Кайдан килеп чыккан нәрсәләр икән соң алар?

Хәйри *(ачуланып, гади мәсьәләне аңламаганга борчылып).* Атаң башы! Чехмы-мехмы – безгә барыбер түгелмени? *(Бераз сабырланып).* Чех ди шул, чех ди...

Вәли *(җитди).* Әткәй, алар килгәч элеккечә тора башларга булырмы икән?

Хәйри. Шулай булыр, шулай! Сәвитне бетерә, ди, җир-суны элекке хуҗаларына кайтара, ди. Сату-алу эшләренә полный ирек бирә, ди. *(Сакалын сыпырып, Зөһрәгә карап елмая.)* Йөзгә ал да меңгә сат! Иртәгә үк, Алла боерса, кибетеңне ачарсың да яшергән товарларны чыгарып сату итә башларсың... Сиңа тагы ни кирәк?

З ө һ р ә *(шатлыгыннан күзләрен ялтыратып елмая).* Ходаем, ул көннәр яңадан кайтты, күрәсең, – минә бәхет!

В ә л и . Бик ашыгырга ярамый. Килеп җитмәгәннәр бит әле...

Х ә й р и . Юкны сөйләмә: җиткәннәр инде! Ярый, бар, чыгыгыз эшегезгә! *(Тегеләр чыга башлый, Хәйри тагын чакыра).* Туктагыз, тукта! Шатлыгымнан иң кирәк нәрсәмне оныта язганмын... *(Вәлигә).* Әле генә миннән алган кәгазьне Намаҗанга бир дә аның белән икәү Әтәч Садыйк йортына, теге элекке земски нәчәлник Митрий Степанычка барыгыз. Кеше күрмәсен, ындыр артыннан ипләп йөгерегез... Анда Аксак бояр, Карун Гали, Кәҗә Якуп, Тукран Хаҗи, тагы кемнәр булыр. Алар ни кушсалар, шуны эшләгез. Бар, сак йөре... Серне чыгарма. Әткәй озакламый килеп җитә диң... Бик ашыгыч эш булса, миннән башка ук карасыннар дип әйтте диң!.. Аңладыңмы?

В ә л и *(шатланып, җиңел атлап ишеккә бара).* Аңладым, киттем...

Х ә й р и . Тукта әле, тукта! Мин барганны көтмичә үк, теге Гомәр Гаязов әйткән большевикларны күзәтү өчен вокзалга, кымызчылар ята торган башкорт авылларына берничә кеше җибәрсеннәр...

В ә л и . Ярар, ярар. *(Чыга).*

З ө һ р ә . Ходаем, шатлыктан йөрәгем урыннарыннан кузгала... *(Иренә иркәләнеп).* Элекке кебек тагы рәхәт тора башлыйбыз, күрәсең! *(Елан кебек, иренә сыена).*

Х ә й р и *(Зөһрәне җиңелчә кочаклап).* Кара әле син, яңа исемә килеп төште: элекке заманда старшина булып торган кылый күз Сафаның хатыны Бәдрия белән серләрең пешә бугай синең.

З ө һ р ә *(иркәләнеп, матур елмая).* Пешә, бик пешә, – без бит аның белән күптәнге ахирәтләр.

Х ә й р и . Алайса бик яхшы: син башыңа калын шәл генә ябын да хәзер үк шунда барып кайт; курыксаң, үзең белән ялчы Әптерәш картны ал.

З ө һ р ә *(бераз аптырап китә).* Ни бар анда миңа мондый җиде төн уртасында?

Х ә й р и *(шелтә белән).* Булмаса, әйтмәсләр иде, бар шул, бар: син башка берәр йомыш тапкан бул... Аларда теге вакыттан калган медаль белән мөһер бардыр – шуны алып-кайт!

З ө һ р ә *(аңламыйча).* Ул нәрсәгә безгә?

Х ә й р и . Безнең күп киңәшләр булды. Аксак бояр әйтә, бүген төндә килеп җитәләр, ди. Җитмәсә дә, болар качып бетә; без иртәгә таңнан ук волость конторы белән вокзалны кулга алабыз да эш башлыйбыз... Тегеләрнең китми калганнарын, кырырга тотынабыз, ди. Мине старшина итеп сайлыйлар, Митри Степанычны вокзал коменданты итеп куялар...

З ө һ р ә *(җиңел, шат атлап чыга башлый).* Ярый, бетте, аңладым. Хәзер барам.

Х ә й р и *(Зөһрә артыннан ишек ябылуга тагын кычкыра).* З ө һ р ә, З ө һ р ә ! Бер эш калган, Вәлигә дә әйт, ул да керсен!

Ш ә н г ә р ә й *(урам як тәрәзәдән шакылдата, карлыккан ашыгыч тавыш белән).* Хәйри абзый, өйдәме син?

Х ә й р и *(тәрәзә шакылдата башлауга ишеккә йөгерә, аннан ашыгып килеп кергән Вәли белән Зөһрәгә бәрелә, аларны төрткәләп чыгара башлый).* Кирәкми, кирәкми, кермәгез!.. Сәвит прсидәтеле[1] килгән... *(Тиз үк барып тәрәзәгә килә).* Кем бар дип торам, үзебезнең прсидәтел, Шәнгәрәй туган, син, икәнсең? Ни хәбәр бар?

Ш ә н г ә р ә й . Артык хәбәр юк... Син, Хәйри абзый, хәзер пар ат белән яхшы арбаңны ылауга җик! Ярты сәгать эчендә әзер булсын! Ишеттеңме?

Х ә й р и *(башын кашый, мескенләнгән тавыш белән).* Син, Шәнгәрәй туган, мине бераз кызган инде: һаман, һаман мине генә йөртәсең... Бу вакытта атларны каян табарга кирәк?.. Яхшы арбам минем юк та... Юк дип, бөтенләй юк түгел инде... Булса да, барыбер эшкә ярамый... Төзәтергә дип урыска – тимерчегә илтеп ташлаган идем, ике айдан бирле шунда ята...

Т и м е р к ә й *(Хәйри белән Шәнгәрәй сөйләшә башлагач та килеп керә. Аягында иске оек-чабата, башында ямьшәйгән начар кәләпүш, өстендә керле киндер күлмәк, ертык камзул. Ул, сүзләрне бик дикъкать белән тыңлаган хәлдә, кулындагы тәмәкесен мич янындагы лампадан яндырып ала да шелтәле тавыш белән).* Их, бабакай, бабакай! Карт башың белән ничек бу чаклы ялганларга оялмыйсың?! *(Тәрәзәгә килеп).* Кәмитит абзый, ышанма бу картка! Ул күзеңә карап ялганлый: аты да, арбасы да бар. Һәммәсе яшерелгән! Кирәк булса, үзем барысын да җәһәннәм астыннан өстерәп чыгарырмын... *(Өзеп, кисеп, бармагы белән саный башлый).* Кендекләр[2], камытлар мунча башында... Тәгәрмәчләр әвен[3] базында. Яхшы тарантас ындырда – кибәннәр арасында саламнарга күмелгән... Атларны караңгы төшкәч кенә елга аръягына, тал куагы эченә бәйләп куйдылар.

Х ә й р и *(аптырап, шашып тора да кинәт Тимеркәйгә ташлана).* Син бала шәйтанга ни калган? Җыен тузга язмаганны сөйләп йөрергә?! *(Кулы белән тәрәзәгә күрсәтеп).* Адәм ышандырырсың бит!

Ш ә н г ә р ә й *(тәрәзәдән каты шелтә тавыш белән).* Хәйри абзый, мин ике сөйләргә яратмыйм, мөгаллимә Камәр китәргә ашыга: ярты сәгатьтә

---

[1] *Прсидәтеле* – председателе.

[2] *Кендекләр* – арбага алгы күчәрне тоташтыра торган кыска тимер таяклар.

[3] *Әвен* – яңгырлы вакытта урылган ашлыкны киптерү өчен тирән баз һәм шуның өстенә корылган куыштан гыйбарәт.

атларың җигелгән булсын! *(Китә).*

Хәйри *(Тимеркәйнең өстенә килә).* Син, дуңгыз баласы, яшь кенә башың белән ни дип миңа каршы тавыш күтәрәсең? *(Сугарга дип, почмактан таяк ала. Тимеркәй аны тота, карт бераз тынычлана, тәһдид белән).* Ярар, ярар, бер-ике көн үтсен әле: бирермен мин сиңа кирәгеңне!

Тимеркәй. Тапты бер сүз! Имеш, бер-ике көн үтсен әле! Бер-ике көн үтсен әле! *(Хәйринең күзенә текәлеп).* Син мине чехтан ашатмак буласыңдыр! Бик исем китте, ди, синең чехларыңа! – Әле дә унбиш ел эт урынына йөрттең! *(Гүя үзалдына сөйләнә).* Бу соңгы вакытта карт бераз йомшаган иде, чех тавышы ишетелә башлагач, тагы сырт йоннарын кабартты... *(Мендәрләр арасыннан нидер эзләп маташкан Хәйринең янына бара).* Ә син, бабай, юкка авызыңны күбекләтәсең: монда калып, сезнең этләрегездән талатыр хәлем юк... Мин мөгаллимә апам белән китәм... Батырхан җизнине ерак та түгел чехлар белән сугыша диләр... Аны эзләп табам да әйтәм: менә мин сиңа килдем, мине теләсәң кая куй, дим... Ул әле кереп тә чыгармын дигән. Аны бүген авылда көтәләр.

Хәйри *(аяк тибеп кычкыра).* Китмәгәең, кадал! Җәһәннәм астына кит! Син эткә унбиш ел буенча ашаткан ашларым хәрам булсын!

Тимеркәй. Бик харап ашаттың инде! Әнкәй мәрхүмне, эткәй үлеп, бу йортка кайткач, яшь хатының Зөһрәгә кол иттең. Ялчы катын урынында тирес түктереп, мал абзарында чертеп үтерттең... Мине җиде яшьтән акчасыз ялчы ясадың. *(Өс-башына күрсәтеп).* Кара боларны! Бу нәрсә бу? Юньле кешенең ялчысы да болай сәләмә йөрми, болар белән адәм күзенә күренергә оят бит!

Хәйри *(таякка үрелеп, тагын аяк тибеп кычкыра).* Җитәр дим сиңа, эт баласы! Югал күземнән!

Тәрәзәдән тавыш *(Батырхан тавышы).* Иванов иптәш, тукта әле, шул йорт бугай. *(Кемдер: «Ту-у... ту-у...», – дип кычкыра).*

Хәйри *(яшен суккан кебек аптырап, катып кала).* Бу кем? Шул каторжник кайттымы әллә? Бу нинди гөнаһ шомлыгы тагын?

Тимеркәй *(сүздән, йөрүдән кинәт тукталып, бик дикъкать белән урамга бер генә секунд колак сала да).* ...Батырхан җизни тавышына охшый. Әллә ул кайтып җиттеме? Менә бәйрәм булыр иде! *(Шатлыктан атылып чыгып китә).*

Зөһрә *(Тимеркәй чыгуга коты очып килеп керә. Башында калын шәл).* Атасы, бу нинди хәл тагы? Мин тегендә барырга дип чыксам, капка төбенә атлар килеп туктады. Әллә нинди солдатлар күренә. Арада теге каһәр төшкән каторжник Батырхан тавышы да бар кебек... *(Якын ук килеп, иренә сыена).* Күңелем «шу» итеп китте... Ходаем, ул разбойникны ник һаман асмадылар

икән?!

Хәйри. Белмим, катын, белмим... Минем башым кабак булды инде! *(Ни эшләргә, ни дияргә белмичә, икесе дә баскан җирләрендә катып калалар.)*

Тимеркәй *(каты басып, йөгереп килеп керә, шатлыктан күзләрендә ут яна, ашыгып кычкыра).* Бибизәйния апа, Фәтхия әби!.. Сөенче! *(Өйдә боларның берсе дә күренмәгәч, кире чыгып йөгерә. Тыштан аның шатлыклы тавышы килә)* Батырхан җизни, Батырхан җизни!.. Сине дә күрер көн бар икән!.. Менә нинди шатлык...

Батырхан *(ике кызылармеецка култыкланып килеп керә. Зур буйлы, карасу йөзле,ябык, ләкин үткен, каты карашлы. Өстендә кызыл командирлар киеме, аяклары, башы, яңаклары, муеннары ак белән бәйләнгән, берничә җирдән аз гына кызарып, кан сирпеп тора. Аны урындыкка утырталар. Үзен култыклап керткән Иванов белән Шакировка урын күрсәтеп).* Рәхмәт, иптәшләр... Утырыгыз шунда *(Зөһрә белән Хәйригә).* Исәнмесез!

Хәйри, Зөһрә. Аллага шөкер, кияү... Үзең исәнме?

Батырхан *(бераз борчыла төшкән тавыш белән).* Бибизәйния белән Фәтхия әби исәндер бит, аларга әйт әле, Тимерхан туган.

Тимеркәй. Исәннәр, бик исәннәр, хәзер керәләр. Алар сине сагынып үлә яздылар. *(Һичкемнән сорамыйча, караваттагы түшәк-ястыкларны бер башка өя дә, авыруга арка терәп утырырга җайлап урын ясый).* Батырхан җизни, Батырхан җизни!.. Әйдә монда утыр... Сиңа авыру кешегә уңай булыр. *(Батырханны култыклап ала, көчләп диярлек караватка китереп утырта).*

Батырхан *(бераз елмаеп, иркәләнгәнрәк тавыш белән).* Рәхмәт, туган, Тимерхан!

Бибизәйния *(ашыгып килеп керә).* Җаным, бәгырем!.. Синме? *(Иренең кочагына ташлана).*

Фәтхия *(Бибизәйния артыннан килеп керә).* Исән кайттыңмы? Балам, бәгырем!.. *(Ике куллап күрешә, урындыкка Батырханга якын ук утыра).*

Батырхан *(кулы белән Зәйниянең башыннан акрын гына сыйпый, Фәтхиягә).* Бик исән тордыңмы, әбкәй, мине бөтенләй югалткансыздыр инде...

Фәтхия *(елый, җиңе белән күзләрен сртә-сөртә).* Әйтмә инде, балакаем, көн еладым, төн еладым... Минем аһ-зарларым Ходай тәгаләгә иреште, күрәсең...

Батырхан *(Зәйниянең башын күтәрә, иркәләү тавышы белән икесенә дә).* Елама, әбкәй, елама, Бибизәйния... Йә, сөйләгез... Нихәлләрегез бар?

Зәйния *(бераз тынычлана, башын күтәрә, үз күзләренә ышанмаган*

*кебек, хәйран булып, шатлык катыш аптырау белән иренә сыена да, йөзен читкәрәк борып, Батырханның күзләренә текәлә).* Ходаем, Ходаем, синме бу? Җиде ел көттем... Сине уйлый-уйлый акылдан шаша яздым... Мине «хыялый Зәйния» дип йөртә башладылар, инде бары да, бары да бетте... Мин хыялый түгел... Мин сине сагынудан гына шулай булдым...

Батырхан *(Зәйнияне иркәли).* Аңлыйм, акыллым... аңлыйм. Мин сине бервакытта да хәтеремнән чыгара алмадым... Шулай да якын арада сиңа кайта алырмын дип өмет итә алмый идем... Тик менә чех сугышы[4+] мине бу якка китерде...

Зәйния *(иренең яңагындагы яра бәйләүләрен карый).* Бик каты түгелме? Бик авыртмыймы, бәгырем... *(Тиз генә шкафтан чынаяк өсте белән су ала да, кесәсеннән ак яулык чыгарып, сак, акрын юа башлый).*

Батырхан. Юк, Зәйния, юк... Куркынычлы яра түгел... Тиз төзәлер ул... *(Баядан бирле икесе ике җирдә катып торган Хәйри белән Зөһрәгә карап).* Сезнең нихәлләрегез бар? Дөньяны бик шәп көтәсезме?

Хәйри *(кашын, маңгаен җыера, дәртсезләнә).* Ни булсын инде, кияү. Чыкмаган җан бар, шулай торабыз инде... Җир-суыбыз китте... Сату-алу бетте. Ни үтермиләр, ни яшәтмиләр. Үз малыңа үзең хуҗа түгел... Мең газап белән җыйган малыңнан хәзер җыен хәерче, эшлексез ялкау халык файдалана. Тормыш түгел, җәһәннәм инде. Ходайдан әҗәл телибез... Башка калмады... *(Бераз туктап).* Синең үзеңне, кияү, нинди җил бу якка ташлады?

Зөһрә *(агарынып, кибеп).* Безнең Батырхан кияү бик зураеп кайткан ахры... Безнең белән юньләп исәнләшмәде. Начармы, яхшымы – мин сиңа ана... *(Зәйниягә күрсәтеп).* Мин синең хатыныңны көндәш кызы дип читкә какмадым. Үз баламнан артык кадерләдем.

Батырхан. Бик рәхмәт, карасаң. Теге вакытта Зәйниягә каршы кылган усаллыкларыңның беразы җуелыр.

Зөһрә *(гүя үзалдына сөйләнгән кебек).* Кияү, аларны хәтерләмә инде. Син үзең дә безне бөтен дөнья алдында хур иттең. Бу йортка моннан соң аяк басмам дигән идең... Туган ил тарта, күрәсең. Әле тагын безне искә төшергәнсең... Ул вакытта да мин сиңа, бик шашма, дигән идем... Коега төкермә, яңадан үзеңә эчәргә туры килмәсен дигән идем... Сүзләрем дөрес чыкты... *(Истиһза[1] белән елмая. Бераз иркәләнгән тавыш белән).* Син, кияү, боларны күңеленә авыр алма, мин үз күргәнгә генә әйтәм. *(Һәммә кеше бераз кузгалышып, йа Ходай, тагын талаш китәме дигән кебек, Батырханга бераз куркынып карыйлар).*

Батырхан *(истиһза белән җиңелчә көлә, тәмәкесен ураган хәлдә).* Ә

---

[1] *Истиһза белән* – мыскыллап, хурлап.

алаймы?.. Мин сезнең тел төбегезне бик яхшы аңлыйм. *(Хәйригә дә, Зөһрәгә дә күз ташлый).* Юкка котыгыз очмасын, мин сезгә кайтмадым. *(Зәйниянең башыннан сыйпый).* Менә Бибизәйнияне күреп чыгыйм дидем... Мин хәзер китәм... *(Дивардагы сәгатькә карый).* Минем ярты сәгать вакытым калды...

Тимеркәй, Батырхан тәмәке төрә башлагач та, кинәт урыныннан кузгала да, йөгереп чыгып китеп, бер пачка папирос алып керә дә Батырханның янына куя.

Зәйния *(йөрәгенә чәнчегән кебек, кинәт урыныннан сикереп тора да бераз хыялый тавыш белән кычкырып җибәрә).* Ярты сәгать! Ярты сәгать! Ходаем, бу нихәл инде бу?*

Фәтхия *(урыныннан торып).* Балам, бәгырем!.. Җиде ел көттек... Син ярты сәгать дисең! Ходаем, безгә сабыр бир! Түзем бир! *(Яулыгына капланып, тавышсыз гына елый).*

Батырхан *(бераз урыныннан кузгалырга теләп, икесен дә юата).* Ни эшлим соң, бәгырьләрем? Артык торырга һичбер төрле мөмкинлек юк... Безне стансада эшелон көтә... Без сәгать унбергә барып җитәргә тиешбез... Еламагыз... Елама... Мин яңадан тиз кайтырмын... *(Үзе белән килгән Иванов белән Шакировка).* Гафу итегез, иптәшләр, семьям эченә кергәч, мин сезне бөтенләй оныттым... Сез бит ачтырсыз?..

Иванов. Тук түгел, өлгерсәк, чәй эчеп аласы иде.

Тимеркәй. Хәзер, хәзер, иптәшләр, кайнаган самавыр бар. *(Кызуланып чыгып китә).*

Әптерәш *(килеп керә. Батырханны күргә, кулындагы трубкасын оек кунычына тыга да ашыгып Батырханга килә).* Әссәламегаләйкем!.. *(Ике кулын сузып).* Әй, Батырхан туган, гомер булгач, сине дә күрер көн җитте бит...

Батырхан. А... Гаптерәшит бабай, исәнме, саумы! *(Күрешәләр).*

Тимеркәй самавырны кертә, шкафтан чынаяклар, чәйнекләр, күмәчләр, бал-майлар алып куя. Зөһрә белән Хәйри, бу нинди яңа хуҗа дип, шашып караналар.

Әптерәш. Аллага шөкер, балам. Шулай бер көе торабыз инде. Адәмнең күңелендә әүлиялык бар диләр, балам. Бүген Хәйри бай йөдәтте...

---

* 1921 елгы басмада шушы җөмлә килә: *(Уйганып чәчләрен иплэп, яңадан иренең тезләренә каплана да, үкереп җылап йибәрә).*

Син карт, ди, карчыгыңа кайтып кил, ди. Ярый, мин әйтәм, синдә, дим, егерме ел ялчы булдым. Үзем сораганда, дим, җибәрми идең, дим. Еллар имингә булсын, дим, үзең әйтеп җибәрәсең, дим. Карчыкка барырга дип чыксам, түбән очта сине кайта икән дип сөйләделәр. Ишеткәч, кире йөгердем. Әй, туган... адәм баласы, гомер булгач, бер күрешә бит... *(Якын ук килеп, яра бәйләүләрен карый).* Болар бик каты түгелме?

Батырхан. Юк, бабай, юк... *(Тәмәкесен чыгарып).* Бабай, менә сиңа миннән бүләк булсын. *(Бирә).*

Әптерәш. Рәхмәт, балам, рәхмәт!.. *(Иванов белән Шакиров янына килә, аларның киемнәрен, мылтыкларын карап, акрын гына сөйләшеп утыра... Үзе өзлексез Батырханга карый тора, сүзен тыңлый).*

Тимеркәй *(өстәлне тәртипләп бетерә, утырта; Шакиров, Иванов чәй эчә башлыйлар).* Батырхан җизни, син монда күчәсеңме? Әллә шунда утырган җиреңә генә ясап илтимме?

Батырхан. Юк, рәхмәт, туган, минем эчәсем килми. Тик бер чынаяк сөт куйсаң, чыгып киткәндә эчәрмен. *(Зөһрә белән Хәйри берәм-берәм акрын гына чыгып югалалар).*

Әптерәш *(аптырап, болар артыннан карап кала).* Боларга ни булган? Нәрсәгә балтасы суга төшкән кебек йөриләр?

Бибизәйния *(бераз тынычлана, күзен-башын төзәтә дә акрын гына урыныннан кузгала. Иренә).* Мин сиңа юл кирәкләре әзерлим әле... *(Чыгып барган хәлдә).* Ходаем, бу бит төш кебек кенә булып калды инде... Тагын кайчан күрермен инде мин сине?!

Батырхан. Елама, Зәйния, кайгырма, без тиз кайтырбыз...

Фәтхия. Бер дә җибәрмәс идек тә бит: Ходайның кушуы шулай, күрәсең, инде!.. *(Акрын атлап, Зәйния артыннан чыгып китә).*

Тыштан тавыш *(Камәр тавышы).* Батырхан абзый кайткан диләр. Шуны ишетеп йөгердек. Әйдә, Шәйбәк бабай!..

Тимеркәй *(тыштан килгән тавышны ишетүгә, тәрәзәгә барып карый да кызуланып чыгып китә, тыштан килүчеләргә).* Мөгаллимә апа, Шәйбәк бабай! Сөенче, сөенче, Батырхан җизни кайтты...

Камәр *(үзе күренмәс борын тыштан тавышы килә).* Чынмы? Расмы? Менә нинди бәхет! *(Килеп керә; башында кепка, аягында тар кызыл итек, кара юбка өстеннән гимнастерка, муеннан кобур, күн тәмәке савыты асылган, биле кызыл каеш-камәр белән буылган, күкрәкләре калкып, беленеп тора, бөдрәле чәче колак йомшагына җиткереп киселгән; ачык, йөрәктән сөйли; сөйләгәндә йөзе-күзе белән матур елмая. Ишектән керүгә Батырханга ташлана).* Батырхан абый! Батырхан абый! *(Озак кысып күрешә, кулын җибәрмәгән хәлдә).* Исемегез тирә-якны яңгыратты... Күрмичә сезгә гашыйк

булып беттек. Инде үзегезне күрер көн дә бар икән!

Батырхан. Сезне бу хәлдә күрүгә мин бик шат... Мин каторгага сөрелгәндә сез бала идегез әле... Хәзер сез нинди матур, нинди үткен туташ, нинди нык революционерка булып җитешкәнсез!..

Камәр *(сөеп карый, бераз иркәләнгән тавыш белән).* Комплементларны бер якка куегыз да сөйләгез: нинди рәхмәт җилләре* сезне безнең илләргә очыртып китерделәр?.. Шатлыктан йөрәгем кузгала. Бу нинди бәхет! Сөйләгез!

Шәйбәк *(килеп керә; кулында таяк, аягында оек-чабата, өстендә камзул, башында бохар кәләпүше; санап чыгарган кебек өзеп, күкрәк тавышы белән сөйли. Бөтен торышында бер сабырлык, тынычлык сизелә).* Әссәламегаләйкем!.. Батырхан балам, исән-сау кайттыңмы? Алла кушкач, сине тагын күрдек бит. *(Кулларын сузып, Батырханга килә).*

Батырхан. А... Шаһибәк бабай, Шаһибәк бабай! Бик исән тордыңмы? *(Картка каршы урыныннан кузгалырга әйтә).*

Шәйбәк. Кузгалма, балам, кузгалма. *(Тимеркәй китереп куйган урынга утырып, дога кыла).* Бик исән генә йөрдеңме, балам? *(Кызганган йөз белән карап, Батырханның яраларына кулы белән күрсәтә).* Бу яраларың бик зыянлы түгелме, балам?

Батырхан. Юк, бабай, юк, артык зыянлы эш юк... Үзең нихәл, бик картаймыйсыңмы?

Тимеркәй *(якын ук килеп).* Батырхан абзый, мин дә синең белән китәм. Монда калып, чех этләреннән талатыр хәлем юк... Үзең белән бергә аласың бит мине?

Батырхан *(Тимеркәйнең кулын кыса).* Алам, бик алам.

Тимеркәй *(шатланып чыга башлый).* Вакыт бик аз бугай. Мин юл кирәге әзерләргә чыгыйм әле...

Батырхан. Тиз бул! Тимерхан, вакыт кысылды, анда безне эшелон көтә...

Тимеркәй *(кызулап чыгып китә).* Хәзер, хәзер, ике минутта без әзер булырбыз...

Шәйбәк *(Тимеркәйне күрсәтеп).* Яхшы кеше булып чыгар бу егет. Күңелем шулай сизә... Батырхан туган, син әйтәсең, бик картаймыйсыңмы, дисең. Картайган идем. Бик картайган идем... Менә бу соңгы елда күңелем тагы бераз яшәреп тора әле. Синең кебек гайрәтле егетләрне күргәч, дөньяда тагын күбрәк торасы килә башлый. Кайтуыңа бик рәхмәт, балам. Көрәш,

---

* 1921 елгы басмада бу урында: *...фәрештәләре, нинди диңгезләр аша, үзләренең нинди миһербанлы канатларында...*

сугыш, әмма туган илне онытма... Мин сиңа башта бик ачуланган идем. Инде фәкыйрь халык өчен тырышып йөрүләреңне күргәч, барын да кичердем. Хәзер сиңа гомер телим,..

Б а т ы р х а н . Рәхмәт, бабай, рәхмәт!

Ш ә й б ә к . Син бит безнең бу су буеннан бер атаклы ир булып чыктың. *(Бераз исәпләп).* Син минем зур кызым Фатима үлгән елда киткән идең... Җиде ел үтеп, сигезгә чыккан була... Күпне күргәнсеңдер, балам.

К а м ә р *(яратып-сөеп, картка карап тора. Матур елмаеп, бераз иркәләнгән тавыш белән Батырханга).* Батырхан абый, сезнең хакта әллә ниләр сөйләп бетерделәр. Сезне бик караладылар. Чынын гына үзегездән ишетәсебез бик килә... Сөйләрсез бит?

Б а т ы р х а н *(гади, бераз салкынча тавыш белән).* Аның нәрсәсен сөйлисең, Камәр иптәш... Моннан ничек китүләрне беләсездер инде... *(Тәмәке урый башлый).*

И в а н о в белән Ш а к и р о в , чәй эчеп бетереп, чыгып китәләр.

З ә й н и я *(килеп керә. Батырханга якын ук килеп кулын сала).* Кара әле, бәгырем, сиңа юлга нәрсәләр куйыйм?

Б а т ы р х а н *(иркәләп).* Ни теләсәң шуны куй, акыллым.

З ә й н и я . Сиңа дип әллә ничаклы майлар, баллар, казлар әзерләгән идек... Шуларны куйыйммы?

Б а т ы р х а н . Куй, иркәм, куй... Ләкин бик күп булмасын.

З ә й н и я . Ходаем, үз кулым белән кадерләп кенә сыйлармын, хәл җыйдырырмын дигән идем... Төш кебек кенә булды бит бу. *(Сәгатькә карый, чыгып китә).*

К а м ә р . Яратам шул Зәйния апаны!.. Миңа аның йөрәге сөю диңгезедер кебек хис кылына... *(Батырханга).* Мин сезнең сөйләвегезне көтәм.

Б а т ы р х а н *(тәмәкесен яндыра).* Сез ишетмештән беләсездер, Хәйри бай үзенең матур, акыллы, уңган кызы Бибизәйнияне минем кебек атсыз, • йортсыз, җирсез бер галахка бирәсе килмәде... Без күптән яратыша идек. Зәйния, атасының риза булмавына карамыйча, миңа ябышып чыкты... Теге байлар очында карт кулак Кәҗә Якубның улы Саткайны беләсездер, шул Бибизәйнияне баш кодалап йөргән икән... Үзенә эләкмәгәч, Бибизәйния хакында бик күп пычраклар тараткан: мин аның белән йокладым, фәлән-төгән дип сөйләп йөргән. Боларны ишеткәч, Зәйния хурлыгыннан көн-төн акырып елый башлады... Мин түзмәдем... *(Өзеп, санап, ачу белән әйтә).* Балтамны үткерләдем дә, көпә-көндез өенә барып, Саткайның башын өзеп чыктым...

К а м ә р *(куркынып китә, урыныннан сикереп тора).* Ходаем!

Батырхан. Сезгә авыр бугай... Алайса сөйләмим...

Камәр. Юк, юк... Сөйләгез... Шуннан соң?

Батырхан. Шуннан соң... Миңа рәхмәт әйтмәделәр, богаулап, каторгага сөрделәр... Герман сугышы[5+] башлангач, мин каторгадан качтым да башка исем белән фронтка киттем... Бер бунтка катнашканлык өчен яңадан крепостька ябылдым. Революция мине коткарды... Февраль революциясе[6+] вакытында Питербурда эшләдем. Октябрь килгәч[7+], элек Краснов[8+], Корниловларга[9+] каршы сугыштык. Аннан соң Уралга Дутовка[10+] каршы сугышка килдем. Менә чехлар баш күтәргәч, отряд белән аларга каршы киттем. Моннан ике көн элек яраландым...

Камәр *(торып, Батырханның кулын кыса).* Сез нинди бәхетле, Батырхан абый! Сезнең яраларыгызны үбәсем килә минем...

Шәйбәк. Шулай, балам, шулай... Гөнаһың бик зур иде... Фәкыйрь халык өчен түккән каннарың бәрабәренә Аллаһы тәгалә гөнаһларыңны кичерер... *(Кулы белән яраларга күрсәтә).* Болар тиз төзәлерлекме, балам?

Батырхан. Юк, бабай, артык куркыныч түгел... Кабыргада берничә пуля ята... Яңак сөяге бераз җимерелгән... Аякларда да берничә яра бар... Боларга операция кирәк... Хәзер шуның өчен Мәскәүгә китеп барам...

Габдулла *(тәрәзәне шакылдата, һәммәсе карыйлар; Камәр тиз генә ача, аннан бөтенләй сугыш хәлендә киенгән кызылармеец Габдулла күренә).* Агайлар, иптәшләр, бик ач киләбез, туктарга приказ юк. Күпме генә алсагыз да алыгыз. Безгә азрак икмәк белән сөт бирә күрегез...

Зөһрә *(тәрәзәдән Габдулла шакылдата башлаганда килеп керә. Өстәлдәге самавырларны җыеп маташа, тәрәзәгә карап кул селкә).* Гаеп итмәгез. Бездә икмәк сатылмый. Сөтебез дә беткән...

Бибизәйния *(Зөһрә артыннан ук килеп керә дә, Габдуллага карап, кызганып тыңлый).* Бичара, ач киләләр, күрәсең. *(Тәрәзәгә таба атлый).*

Камәр *(Зөһрәгә ачулы бер караш ташлый да аның сүзе бетмәс борын ук).* Хәзер, хәзер табарбыз, иптәшләр! *(Тәрәзәдән солдатның сөт савытын ала. Үзенә каршы килгән Зәйниягә бирә, Зәйния тиз генә чыгып китә).*

Батырхан *(урыныннан кыенлык белән кузгалып, тәрәзәгә таба атлый).* Иптәш, сез кайсы отрядтан?

Габдулла *(тәрәзәдән).* Петров отрядыннан.

Батырхан. Ә! Петров отряды! Алайса сез Шиловканы ташлап чыккансыз?

Габдулла. Ие, Шиловкадан киләбез. Безнең азаккы отряд, башкалар көндез үк үттеләр...

Батырхан *(уйлана, гүя үзалдына).* Мин Петров отряды иртәгә чаклы Шиловканы кулында тота алыр дип уйлаган идем...

Зәйния *(сөт, икмәк күтәреп килеп керә, тәрәзәгә илтеп бирә).* Мәгез, туганкайлар...

Габдулла. Күпме бирик?

Батырхан, Зәйния *(берьюлы).* Юк, юк, бернәрсә дә кирәкми! *(Зәйния чыгып китә).*

Габдулла. Рәхмәт алайса, бик рәхмәт! *(Китә башлый).*

Әптерәш *(тәрәзәгә таба килеп).* Балам, син кем? Тавышың таныш кешегә охшый! Сайфанның Кәримә карчык улы түгелме?.. *(Җавап көтмичә, кызуланып, ишеккә китә).* Тукта, балам... Хәзер чыгып сөйләшәм. *(Чыга.)*

Шәйбәк *(самавырларын күтәреп чыгарга әзерләнгән Зөһрәгә шелтәле тавыш белән).* Зөһрә килен, син Алладан курыкмасаң, бәндәдән оялыр идең... Келәтең тулы иген, абзарың тулы сыер... Ә син: сөт юк, икмәк юк, дисең!*

Батырхан *(истиһза белән көлеп).* Чехлар якынлый бит. Шуларга май җыядыр...

Зөһрә *(зәһәрләнеп).* Ярар, ярар, юк өчен талап бармагыз инде... Башкалардан талануыбыз да җитәрлек булды...

Шәйбәк. Әстәгъфирулла диң, Зөһрә килен... Башыңның исәнлегенә Аллага шөкер ит... *(Үзалдына сөйләнгән кебек).* Бигрәк юлдан яздылар инде. Канәгать юк... шәфкать юк... Ходайның барлык нигъмәтләрен үз кулларына җыйганнар да бөтен дөньяны үзләренә кол итмәкче, табындырмакчы булалар...

Шәнгәрәй *(керә. Оек-чабата, мескен бүрек, искергән тужуркадан).* Исәнме, Батырхан, бик исәнме! *(Кулын бирә).* Сине безнең югары оч байлары кырык мәртәбә үтерделәр... Кайтып төшүең безгә зур бәйрәм булды...

Зөһрә– Шәнгәрәй керүгә яулыгы белән йөзен каплый да пыр-пыр итеп чыгып китә.

Батырхан. Исәнме, Шәнгәрәй абзый! *(Күрешә).* Син авыл советының председателе бугай... Башка хәлләрне юлда сөйләрбез, син хәзер шуны әйт: яңа вокзалга моннан ничә чакрым, бер сәгатьтә барып җитәрлекме?

Шәнгәрәй. Яңа вокзал бездән ун чакрым. Бер сәгатьтә иркен барып җитәбез... Батырхан туган, син шулай бик ашыгычмыни? Сине безнең ярлылар бик көткәннәр иде, аягың безнең туфракка басмас борын, кайту хәбәрең бөтен авылга таралды... Бүген таңда чех көткән байлар, синең кайту хәбәреңне ишеткәч, яшеннән качкан шайтаннар кебек, сәке асларына,

---

* 1921 елгы басмада мондый җөмлә бар: *Аны кемгә саклыйсың?*

базларга яшеренгәннәр *(көлә),* безнең төбәкләр бәйрәм итә...

Батырхан. Алайса, сезнең монда халык бер-беренә каршы ике класска нык аерылышып җиткән. Сез алайса нык эшләгәнсез.

Шәнгәрәй. Дөнья үзе аера, үзе аера бит! Бездә халык аерылу гына түгел, бай белән ярлы бугазга-бугаз килеп сугышалар инде. *(Якынрак килеп).* Батырхан туган, башка якта хәлләр ничек? Сүзне туры сугыштан, чехтан башлыйк: берсен дә яшермә, барын сөйләп бир. Монда чит кеше юк... *(Камәргә карап).* Мөгаллимә иптәш безнең тирә-якның каһарманы инде ул. Югары оч кулаклары, һәммә усаллык шул марҗадан чыга дип, аны үтерергә йөрделәр... *(Шәйбәккә).* Шаһибәк бабай да безнең үзебезнеке[*] инде ул. Байлар очында «ат азгыны тайга ияр» дип мыскыллыйлар аны.

Батырхан. Шулай, иптәш, шулай, Камәрләрнең, Шәйбәк картларның безнең сафта булуы – яшь җаннарга йөрәк ныклыгы бирәчәк, үрнәк булачак. *(Тәмәкесен яндыра).* Эшләр ничек дисең? Сугыш ягы шәп түгел, иптәш, Кызыл Армия оешып җитмәгән. Арабызга кергән иске офицерлар безгә хыянәт итәләр... Муллалар, поплар, кулаклар һәркайда халыкны саташтыралар, чех-словакны икмәк-тоз белән каршы алырга димлиләр... Самардагы суешларны ишеткәнсеңдер, анда күпме эшче-крестьян каны түгелде!.. Безнең иптәшләрнең башлары өчәр көн урамда аунады.

Камәр *(кинәт сикереп тора).* Нинди вәхшәтләр, нинди ерткычлар!!

Шәйбәк *(бераз тәһдид белән).* Үз башларына кыланалар, үз башларына. Алар кан дәрьясы аша барып, карун булырга телиләр... Аллаһ тәгалә андый усаллыкларга түзмәс, балалар!

Батырхан *(баягы сүзендә дәвам иткән рәвеш белән Шәнгәрәйгә).* Үз арабызда да шәп түгел, куркаклар, шкурниклар, имансызлар бар... Хәзерге вакытта без һәр яктан ут эчендәбез... Бу авыл да зур куркыныч астында: уң кабыргадан Саранов иптәшнең отряды фронт ярып килә... Әгәр ул өлгерә алмаса, бу авылны таңда чех бандасы килеп басачак... *(Акрынрак, артык җитди тавыш белән).* Сез, һичнәрсәгә карамастан, бүген төндә бу авылдан китәргә тиешлесез!..

Камәр. Без китәргә әзерләнеп беттек инде... Шәнгәрәй абзый, син олау китерергә кушкансыңдыр бит?..

Шәнгәрәй *(Камәргә).* Куштым, куштым... Тиздән әзер була... *(Батырханга, аптырап, бераз куркыбрак).* Батырхан иптәш, сезнең эшләр шулай бөтенләй өметсезмени соң?

Батырхан *(кинәт ныгый, урыныннан кузгала, ачы-кискен тавыш белән).* Юк, юк! Алай түгел! Бу – вакытлы җиңелү генә! Безгә, бәлки, Волгага

---

[*] 1921 елгы басмада *үзебезнеке* урынына *пәйгамбәребез* сүзе килә.

чаклы чигәргә туры килер, шул арада без яңадан көч җыеп өлгерербез. Ишеткәнсездер, хәзер бит безнең гаскәр эченә һәркайдан эшчеләр йөзәрләп, меңәрләп агылалар...

Шәйбәк *(урыныннан кузгала башлый).* Өметсез – шайтан, дигән борынгылар... Аллаһ тәгаләнең хикмәтен бер чех килеп кенә боза алмас, балалар... Ул явызлар үзләрен Нәмруд [11+], Фиргавен[12+] урынына мендереп, безне бәни Исраил [13+] хәленә төшергәннәр иде... Бер кат җимерделәр, инде яңадан халык өстенә менә алмаслар алар, Алла кушса... *(Ишеккә таба атлый).* Батырхан балам, кайтуың бик азга икән – син инде Бибизәйнияне юатырга тырыш. Ул бичара бер әүлия катын инде... Кайбер вакыт кинәт урамда туктата да: «Шәйбәк бабай, минем Батырханым кайчан кайтыр икән?» – дип сорый. Шул чакларда күзләреннән яшьләр килә. Тагы керермен, алар янына чыгып, хәлләрен белим әле...

Батырхан. Шәйбәк бабай, сиңа бик рәхмәт, Бибизәйния без киткәч бик борчыла башласа, син юаткаларсың инде.

Шәйбәк. Ярар, балам, ярар. *(Чыгып китә).*

Шәнгәрәй *(сәгатькә карый).* А, вакыт бик азайды, безгә ашыгырга кирәк. *(Урыныннан кузгала. Батырханга).* Син эш арбасында кайткансың бугай. Авыру кешегә ул каты булыр. Анда синең юлдашларың белән мин утырырмын. Сезне *(Камәргә күрсәтә)* менә мөгаллимә иптәш белән Хәйри байның тарантасына урнаштырырбыз. Сезгә кучер булып Тимеркәй барыр. *(Ишеккә җиткән җиреннән кире борыла төшеп).* Гаҗәп бер егет булып чыкты ул безнең Тимеркәй: элгәре Хәйри байның эшеннән бушаган арада уен-көлкедән башканы белми торган бер шаян егет кебек иде... Чех тавышы, әйтерсең, аны йокыдан уятты... Кичә кич миңа килеп, үземне генә чакырып чыгарды да, кәмитит абзый, ди, сез китәсез бугай, ди, мин дә сездән калмыйм, ди. Әйдә, мин әйтәм, барсын, бик йөрәкле күренә, бер каһарман чыкмасмы үзеннән. *(Чыга башлый).*

Батырхан. Шулай, Шәнгәрәй абзый, бу канлы сугышлар сукырларның да күзләрен ачалар...

Камәр *(тәрәзәгә карап).* Безнең бәхеткә, ай да калкып килә, без тизрәк кузгалыйк, иптәшләр.

Батырхан *(Шәнгәрәйгә).* Юлда сөйләшербез, бар син, Шәнгәрәй абзый, атларыңны ашыктыр...

Шәнгәрәй. Ярар*. *(Китә).*

Батырхан *(бераз сүзсез торгач, тәмәке урый башлый, туташның күзләренә карап).* Сездән бернәрсә сорыйсым килә, ачуланмыйсыз бит?..

---

* 1921 елгы басмада бу җөмлә болай: *Биш минутта һәммәсе әзер булыр.*

К а м ә р *(Батырханның тәмәкесен алып ташлый).* Ходаем, шул нәрсәгез белән дөнья сасытмагыз әле. Менә миндә юньлеләрге бар. *(Күн савыттан папирос чыгарып бирә, яндыралар, шелтәле тавыш белән).* Ул нинди сүзегез тагын: «Ачуланмыйсызмы», дисез? Ник ачуланыйм, мин сезнең белән бөтен серләремне сөйләшә алам.

Б а т ы р х а н. Сез шундый матур, шундый кызганучан табигатьлесез! Дөньяда сезнең яшь күңелегез ярата торган башка әйберләр дә күптер, – ничек сез бу канлы көрәшкә атылдыгыз?!

К а м ә р. Төп сәбәбен мин әйтмәсәм дә беләсез: мин бик артык ярлы гаиләдәнмен. Мең газап белән укыдым. Иске тормышның барлык «хозурларын» үз йөрәгемдә татыдым... *(Бераз кыенсынып, идән буена йөргән хәлдә).* Аннан соң... аннан соң... шул да бар: мин беренче сөюемдә тирән бер бәхетсезлек күрдем... Шуның газабыннан дөньяны ташлап, кайгымны күмәр, бераз онытылыр өчен, Уфага курсларга бардым... Анда сөйләделәр... аңладым... Шунда ук партиягә дә язылдым... Хәзер... Хәзер юлым, кыйблам билгеле, җаным тыныч... Элек сөюләр, матур чүпрәкләр колы булуымны уйласам, хәзер үземнең йөзем кызара... Менә сезгә бөтен тарих... Аннан соң минем ялгыз, фәкыйрь энкәмнең язмышы минем өчен бөтенләй икенче төстә күренә башлады... Хәзер ул миңа...

Каты туп тавышы килә башлый.

Ә п т е р ә ш *(ашыгып килеп керә, курыккан тавыш белән әле Камәргә, әле Батырханга карап).* Туганнар, Дүртөйлене[14+] тегеләр алган, ди... Ун гына чакрым кала бит... Сезгә тимәсләрме?..

Б а т ы р х а н *(урыныннан кузгалып, бабайга килә).* Курыкма, бабай... Без хәзер китәбез...

Ә п т е р ә ш *(кызганып, елауга охшашлы тавыш белән).* Балалар, сез бер дә кайтмаска китәрсезмени?

Б а т ы р х а н. Юк, бабай, юк... Күп вакыт үтмәс, бу җирләр яңадан безнең кулга керер.

Ә п т е р ә ш. Шулаймы? Алайса, бик ярый. Мин белмим инде бернәрсә дә...

Т ы ш т а н т а в ы ш. Олауларның барысы да шунда көтәргәме?

Т и м е р к ә й *(керергә дип ишекне ачкач, кире борылып кычкыра. Ул юлча киенгән: иске бүрек, биле җеп белән кысып бәйләнгән, өстендә чикмән, кулында чыбыркы).* Шунда көтсеннәр. *(Батырханга.)* Җизни, шулай китәбез дәмени инде?.. Менә нинди шатлык, валлаһи!

Б а т ы р х а н. Китәбез, китәбез... *(Киенә, ипләнә башлый. Тимеркәй аңа булышлык итә. Батырханга дип әзерләнгән юл төенчекләрен күтәреп, авыр кайгылы йөзле Зәйния, Фәтхия әби, алар артыннан Шәйбәк бабай, бөтенләй*

*ярлы крестьянча киенгән Шәнгәрәй, ни әйтергә аптыраган йөз белән Вәли, Зөһрә, Хәйри бай, ашыккан төс белән, куркынып, Шакиров белән Иванов килеп керәләр. Зөһрә, Хәйри, Вәли сүз дәшми катып торалар. Шәнгәрәй әйберләрне чыгара башлый. Зәйния, Тимеркәй Батырханны иплиләр, киендерешәләр).*

Бибизәйния. Ходаем, син тагы китәсең!.. *(Иренә сыена).* Сине тагын кайчан күрермен инде?!

Батырхан *(Зәйнияне иркәли). Е*лама, үзеңне ватма, Зәйния. Без озакламый яңадан кайтырбыз... *(Киенеп бетә).*

Фәтхия *(елап).* Батырхан балам, сүзләрең фәрештәнең “амин “дигән чагына туры килсен иде инде...

Зөһрә, Вәли, Хәйри – карчыкның, Батырханның сүзләренә каршы, мыскыл иткән рәвеш белән бер-беренә карап елмаешалар.

Зәйния. Шулаймы, бәгырем, тиз кайтырсыңмы? *(Балалар кебек иренә сыена).*

Батырхан *(Зәйния һәм Фәтхия әби белән күрешә, хатынының маңгаеннан үбә).* Борчылмагыз... Без тиз кайтырбыз... *(Ишеккә таба кузгала, нидер хәтерләп, юл сумкасына тыгыла, аннан берничә пакет чыгарып, лампа яктысында карый; берсен алып Ивановка бирә).* Менә моны вокзал комендантына бирергә онытма...

Тимеркәй *(Батырхан пакет белән маташкан вакытта Зәйнияләргә якын килеп).* Шулай, Зәйния апа, шулай, син кайгырма, без тиздән дөбердәтеп кайтып килербез... *(Шәйбәккә).* Шәйбәк бабай, син мондагы буржуйларга әйт: яңадан кайтканда мине икмәк-тоз белән каршы алмасалар, мин аларны ат урынына сабанга җигәрмен... Каганнарын җигеп тырма тырмалармын... Ярыймы?

Шәйбәк *(шелтә белән).* Алай димә, балам... Син изге эшкә китәсең... Яхшы йөр!

Батырхан *(тирәдәгеләргә күз ташлап).* Һәммәгез әзерме? Әйдәгез, киттек! *(Чыга башлый).*

Камәр *(өйнең түрендәрәк Зәйнияне кочаклап, акрын адым белән ишеккә таба сөйләнә-сөйләнә килә).* Елама, кайгырма, Зәйния апа... *(Хыялына китеп, югалгандай өзеп әйтә).* Дошман җиңелер... Бу кан түгүләр бетәр... Җир йөзе гөл бакчасына әйләнер... Адәмнәр матур, бәхетле тора башларлар.

Чыгалар. Алдан, Иванов белән Тимеркәйгә таяна төшеп, Батырхан, аның артыннан башкалар, иң арттан, сөйгән, сагынган бер караш белән өйгә күз йөртеп, Камәр чыга... Рәттән берничә мәртәбә туп,

залп тавышы килә, тышта кемнеңдер: «Ту-у!.. ту-у!..» дип ат кузгатуы, Зәйниянең елавы, Шәйбәкнең: «Аллаһ изге юл бирсен, балалар», – дигән догасы – гомумән, озату вакытындагы шау-шу килә. Тавыш тынгач, З ә й н и я , аның артыннан Ш ә й б ә к б а б а й килеп керәләр.

Б и б и з ә й н и я *(елаудан йөзе бозылган, яулыгы бер якка китеп, чәче тузгаланган; ул урам як тәрәзәгә таба авыр хыялый уйда акрын гына бара, сандык өстендә яткан гармунны, гүя үзе белмәстән, кулына ала, тәрәзәгә карый).* Тагы китте, еракка, еракка китте!.. Мин тагы ялгыз калдым!.. *(Ишеккә таба борылып, бабайны күргәч, кинәт аңа ташлана, кулбашларыннан алып).* Әйт,* бабакаем, яңадан кайтырлармы? Минеке дә кайтырмы?

Ш ә й б ә к *(Зәйниянең башыннан сыйпый, йомшак тавыш белән иркәли).* Елама, балам. Елама. Озакламаслар, яңадан кайтырлар, Батырхан да кайтыр!

З ә й н и я *(бераз тынычлана, йөзен күтәрә, бабайның күзләренә йотылып карый).* Бабакаем, бабакаем!.. Син нинди изге, нинди яхшы күңеллесең! Нигә һәммә кешеләр дә синең кебек түгел! *(Шул хәлдә сүзсез, хәрәкәтсез калалар).*

Акрын гына пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

К А Т Н А Ш У Ч Ы Л А Р

А н д р е е в – зур, таза гәүдәле, матур йөзле, зур мыеклы рус офицеры; бөтенләй борынгы офицерча киенгән, үзен шулай тота; алпавыт баласы, сабыйк студент[1]. Аңарда алтын погоннар, бинокль, хариталы[2] юл дәфтәре, кобур эчендә наган, 38 яшьләрендә.

Г а л и м о в – яшь татар прапорщик. Андреевның мөгавине[3], хәрби шурачы

Ч е х – зур, таза гәүдәле, баштанаяк коралы; үзләренең мәгълүм милли хәрби киемнәрендә.

А к с а к б о я р К о л и н к и н – сабыйк алпавыт; зур ак сакаллы, зур чәчле; америкaн итек, яңа бәрхет поддевкадан, 60 яшьләрендә.

М и т р и С т е п а н ы ч Г р и г о р ь е в – сабыйк земский начальник, борынгы рәсми киемдә.

Х ә й р и б а й – беренче пәрдәдәгедән күп яхшы киенгән; сәгать

---

* 1921 елгы басмада монда : *җаным* сүзе бар.
[1] *Сабыйк студент* – электә студент булган.
[2] *Хариталы* – географик карталы.
[3] *Мөгавине* – урынбасары.

чылбыры ялтырый, күкрәгендә иске старшина медале.

Беренче мулла – чалма-чапаннан, зур, мәһабәт кыяфәттә.

Икенче мулла – җиләннән, ак бүректән, кулында яшел таяк.

Ике поп – рәсми киемнәреннән, күкрәкләрендә зур көмеш тәреләр.

Әхтәм Банаев – милләтче татар зыялысы, милли идарәче; камил «европача» киемдә: ак панама, галстук, яхшы тройка, сары шиблет.

Камәр мөгаллимә – кыйналган, йөзе яралы; *канлы гимнастерка, башында иске яулык.

Батырхан – кыйналган, газапланган, фуражкасыз; изүләре ертылган, йөзендәге яра бәйләүләреннән кан бәреп чыккан.

Шәнгәрәй – бөтенләй элекке төсендә.

Тимерче Гайнетдинов – совет вакытында волость комиссары; ярлы крәстиәннән; өсте-башы начар, бөтенләй корымлы.

Тимеркәй – беренче пәрдәнең ахырында китәргә дип киенгән рәвештә, чыбыркысы да кулында.

Семенов – Кызыл Армиядә 13 нче полк командиры, контрреволюция белән яшерен мөнәсәбәттә, аларның яшерен агенты, ак офицер.

Шәйбәк бабай.

Насыйб }авыл ярлыларыннан яшь егетләр, оек-чабата,

Ярми } авыл эшләпәсе кигәннәр.

Җамали – авыл кешесе, ярлы киемдә, кычкырып сөйли; кулында һәрвакыт зур күн бияләйләр, 40 яшьләрдә.

Вәли, Зәйния, Зөһрә, Әптерәш, ике баласы белән Гөлҗамал, Фәтхия карчык, командир Саранов, аклар, кызыллар, кулаклар, авыл ярлылары, хатын-кыз, бала-чага, Иванов, Шакиров, каравыл башлыгы, Емельянов, ак күзәтче, ике кызыл күзәтче.

Пәрдә ачылганда болытлы, яңгырлы җәйге көн. Авылның бер чите. [15+]Волость конторы. Конторның тәрәзәсе турынарак китереп өстәл куелган, аның тирәсендә урындыклар, эскәмияләр, өстәлдә ниндидер кәгазьләр, берничә гәзит, каләм, кара савыты, бер кобур*; конторның ишеге төбендә агач болдырның өченче катына басып кораллы солдат тора. Пәрдә ачылганда, күренеш шушы тәртиптә:

Өстәл тирәсендәге урындыкларда,* иң уртада,*** зур трубкасын тартып,

---

* 1921 елгы басмада: *кыйналган, йөзе яралы; канлы, гимнастерка юк, җыртык кофточкадан, башында иске яулык.*

* 1921 елгы басмада монда *портфель* сүзе килә.

** 1921 елгы басмада монда: *...эскәмиядә җыенның башлыклары....*

*** 1921 елгы басмада монда:*...бераз арткарак каерылып һавалы, ләкин бераз ялыккан*

чех утыра; аның уң ягында [****]– офицер Андреев, чехның сул ягында – Галимов.[*****] Боларга терәлеп, бер яктан – элекке земский начальник Григорьев, икенче яктан – Тимофей Колинкин; Галимов белән Григорьев уртасында – Әхтәм Банаев; алардан арттагы рәттә, эскәмияләрдә, бернichә[******] кулак; иң күренекле урында – поплар белән муллалар, алар тирәсендә аягүрә басып – рус, татар, мукшы авыл байлары...

Боларның һәммәсенең артында, ниндидер бер биегрәк нәрсәгә басып, бакча читәненә сөялә төшеп, Шәйбәк бабай хәйран булып карап тора.

Өстәлнең алдында бер сажин чаклы урын буш калдырылган. Бу бушлыкның сәхнә түренә таба ягында кылычлы, мылтыклы солдатлар белән уралып, тоткыннар тезелгән. Тоткыннар шушы тәртиптә:

Иң алда – мөгаллимә Камәр, аның янында – Батырхан; боларга терәлеп үк Шәнгәрәй, Гайнетдинов, Шакиров, Иванов, Семенов торалар.[16+]

Пәрдә ачылган чагында җыелышның иң кызу барган чагы. Аксак бояр Колинкин, көмеш башлы таягына таяна төшеп, сүзен дәвам иттерә.

Колинкин. Менә шуның өчен дә, господа, без: яшәсен каһарман чехословак кардәшләребез! дибез. Шуның өчен дә: яшәсен бүленмәгән бөтен бөек Россия! дибез.

Хәйри, Вәли, алар артыннан башкалар *(гөж килеп кул чабалар, шаулап кычкыралар).* Яшәсен чехлар! Яшәсен чехлар! Ура! Ура!

Өстәлгә якыннар, җәмәгатьнең алдагылары шашып шаулашканда, арттарак торган ярлылар эченнән Насыйб белән Ярми бер-беренә нидер әйтеп арткарак чигенәләр. Ярлыларның кайберләре, аптырап, як-ягына каранып, күрсәләр яхшы түгел дигән кебек, теләми генә кул сугалар. Тоткыннарның йөзе көя, тик Батырханның йөзендә генә истиһзалы елмаю сизелә. [*]Колинкин сүзен бетерүгә, җәмәгать шаулаган вакытта, Әхтәм Банаев Андреевка, чехка нидер әйтә; "ярар инде" дигән кебек, баш селкәләр; Андреев бер генә сүз язып Банаевка кире кайтара.

Әхтәм Банаев *(аягүрә баса, пенснене ипли, җәмәгать тын була).*

---

*кыяфәт белән...*

[****] 1921 елгы басмада монда:..*бүген таңда гына бу авылны килеп баскан фирканең командиры рус офицеры Андреев...*

[*****] 1921 елгы басмада монда: *Буның төсеннән үк татарлыгы күренеп тора. Ләкин ул мөмкин кадәрле ак офицерларча киенергә тырышкан. Үзен шуларча тотарга тели, ара-тирә төзәтенә, Андреевка карап ала.*

[******] 1921 елгы басмада монда:..*бернichә калын корсаклы, кызыл җилкәле кулак...*

[*] 1921 елгы басмада бу җөмлә болай: *Колинкин сүзен бетерүгә, җәмәгать шаулаган вакытта, Әхтәм Банаев Андреевка бер записка бирә. Бусы тиз генә укый да, чехка нидер әйтә; икәү карашалар, уңайсызланган хәлдә"ярар инде" дигән кебек, баш селкәләр...*

Әфәнделәр, бөтен Русия өчен, аеруча безнең милләтемез һәм оешмаларымыз өчен зур һәлакәтләр китергән, әйтеп бетергесез афәтләр тудырган советлардан котылдык... Безнең милли идеалымызны гамәлгә куюю сәгате сукты... Миннән элек сөйләгән хатыйб[1] әфәнделәр дә әйтеп үттеләр ки, бу олуг сәгать, бу бөек милли бәйрәм безгә *(чехка, Андреевка карый)* иң фидаи чех-словак борадәрләремез[2] аркасында гына насыйб булды, тик аларның канлы штыклары гына безгә азатлык китерде... Буның өчен без каһарман чех-словак туганнарымызга ничаклы тәшәккер итсәк, кинә аз булачак; бу бөек каһарманнарның олуг хезмәтләре безнең милли азатлыгымыз тарихында алтын хәрефләр белән язылачаклар... Менә шуның өчен дә без: яшәсен чехлар! димез. Яшәсен безгә азатлык бирүче туганнарымыз! димез...

Хәйри, аның артыннан өстәл тирәсендәге һәм алгы сафтагылар (*бары берьюлы кычкыралар):* «Яшәсен!.. Яшәсен чехлар!.. Мең ел яшәсен!»

Шау-шу, кычкыру дәвам иткән вакытта арттан кемдер бик ачы сызгырып җибәрә. Бу халыкны яшен суккан кебек ясый: өстәл тирәсендәгеләр, кинәт сискәнеп, башларын күтәрәләр, караналар, Хәйри дулап йөгеренә башлый, тик Андреев кына сер бирмәскә тырыша.

Андреев *(хатыйбка).* Дәвам итегез!! *(Халыкка).* Тынычланыгыз, җәмәгать, тынычланыгыз!!

Әхтәм Банаев. Ләкин, әфәнделәр, коры сүз, коры рәхмәт белән генә эш чыкмый! Кызыл дошман моннан куылса да, бөтенләй бетерелмәгән әле... Аның бандалары моннан ун-унбиш чакрымда сугышып азапланалар... Бу кызыл бандаларны юк итәр өчен, бу совет дигән кара мәлгунь нәрсәне җир йөзеннән себереп түгәр өчен без бөтен көчемез белән чех-словак кардәшләремезгә ярдәм итәргә тиешлемез... Бу – безнең милли карызымыз[3]! Мин, әфәнделәр, бөтен төрек-татар милләте исеменнән газамәтле[4] чех-словак гаскәренә актык канымызгача ярдәм итәргә ант итәмен... Җәмәгать, шуңа кушыласызмы?

Җәмәгать *(өстәл тирәсендә, мәйданның алгы сафындагылар гөж килеп кул чабалар, шаулашалар).* Кушылабыз, кушылабыз!

Галимов *(аякка баса, халык аз гына тына).* Мин, җәмәгать, Казан хәрби шурасының [17+] вәкиле сыйфаты белән, чехларга ярдәм өчен мөселман полклары, мөселман эскадроннары төзергә тәкъдим итәм.

Җәмәгать. Төзибез... Полклар, эскадроннар төзибез... Хәзер сугышка китәбез... *(Гөж килеп кул чабалар, шаулыйлар; арттан кемнәрдер рәттән*

---

[1] *Хатыйб* – оратор.
[2] *Борадәрләремез* – кардәшләремез.
[3] *Карызымыз* – бурычыбыз.
[4] *Газамәтле* – данлы, шанлы.

*берничә мәртәбә бик каты сызгырып җибәрәләр).*

Чех урыныннан сикереп тора. Ачулы күзләре белән халыкка кадала. Аксак бояр. Григорьев сикереп торалар. Аптырап, шашып бер җәмәгатькә, бер чехка караналар. Андреев, агарынып, тешләрен кыса, янындагыларга нидер әйтә, тынычландырырга димли.

Хәйри бай *(җенләнеп, шашып кычкырып җибәрә, үзе, таягын селкеп, җәмәгать эченә барып керә, йөгерә, эзләнә).* Кем ул? Кайсы ләгънәте безнең бәйрәмебезне пычрата?! *(Берәм-берәм барып тотына).* Әйт, кем сызгырды? Башын сугып ярыйм мәлгуньнең!

Җыелышның яме югала, мәйданның арттагылары читкәрәк китәләр... Кайдадыр туп атылганы ишетелә. Кайберәүләр як-якка каранып югалалар. Беренче мулла акрын гына кузгалып сыза.

Андреев *(кинәт кузгалып, уртага чыга, Хәйрине туктата, өстәлдәгеләргә нидер ашыгыч әйтә; ризалата, уң кулы белән тоткыннар ягын күрсәтә).* Җәмәгать, менә шул якны бөтенләй бушатыгыз. *(Хәйри куа башлый, җәмәгать, коты очып, артка чигенә).* Емельянов, боларны *(тоткыннарга күрсәтә)* менә шунда, безнең каршыгарак китерегез! *(Галимовка нидер әйтә, үзе яңадан утыра. Емельянов тоткыннарны өстәлгә якынрак күчерә. Андреев Галимовка).* Башлагыз!

Галимов *(бераз каушап, ашыгып, портфель актара. Аннан бер кәгазьне ала да калтыранган тавыш белән укый).* Габдулла Сәйфулла углы Гайнетдинов; яше утызларда, Карамалы[18+] крестьяны, тормышы Дүртөйледә, кәсебе – тимерчелек; волостьта комиссар булган, Тимофей Колинкинның имениесен талаган, җир-суын алган, Федор Колинкинны атып үтергән.

Андреев *(урыныннан тора, өстәлнең тоткыннарга караган ягына чыгып, нидер уйланган, ачуланган рәвештә бер кулы белән кобурына тыгылып, гасаби хәлдә йөренә, тоткыннарга карап).* Кайсыгыз тимерче комиссар Гайнетдинов? *(Гайнетдинов алгарак чыга).*

Андреев *(ачулы караш белән аңа кадала).* Синме?

Гайнетдинов *(аз гына да каушау әсәре күрсәтмичә).* Мин булам!

Андреев *(ачы, каһәрле тавыш белән).* Тимофей Колинкинның имениесен талаучы синме? Федор Колинкинны атып үтерүче синме?

Гайнетдинов *(тирә-якка күз ташлый, элекке тынычлыгы белән).* Мин волость исполкомының постановлениесе буенча аның йортын Дүртөйле авылына мәктәпкә, клубка алдым... Ашлыгын ачларга тараттым... *(Кулы белән Аксак боярга күрсәтә).* Господин Тимофей Колинкин үзе дә әйтер: без аның агасын бер заговорга катнашканлыгы өчен хөкем белән аттырдык.

Аксак бояр *(берьюлы кычкырып җибәрәләр, куллары белән*
} *Гайнетдиновка күрсәтәләр).* Ялганлый, собака!

Х ә й р и } Ялганлый! Бөтен тирә-якны шул талады, шул атты!
В ә л и }
һәм
б а ш к а л а р }

А н д р е е в *(кызып, гасабиланып, елмаеп кына кул селкә).* Разбойник Гайнетдиновны читкә чыгар! *(Емельянов аны тотып арткарак чыгара башлый).*

Г а й н е т д и н о в (аз гына да тартынмыйча, Батырхан белән Камәргә кул бирә). Бәхил булыгыз*!.. (Насыйб, Ярми, Әптерәш, алар артыннан башка ярлылар да кысылып-кысылып Гайнетдиновка таба барырга кузгалалар, Хәйри аларны кире чигендерә).*

А н д р е е в *(ачы, каты тавыш белән сүзләрен санап чыгара).* Кеше милкенә кагылучыларга менә бездә шул закон! *(Наганын тотып ала да рәттән ике мәртәбә ата; җәмәгать гөж килеп ике якка аерыла; Гайнетдинов сүзсез-нисез егыла; бала-чага, хатын-кыз акырып елап җибәрәләр; гадәттән тыш тавыш, елаш күтәрелә, Андреев салкын, гади хәлдә урынына утыра).*

И в а н о в, Ш а к и р о в *(бу атудан котлары очып, каравылның тыюына карамастан, өстәл янына, аяк астына егылалар, шашкан бер тавыш белән кулларын югары таба бутый-бутый кычкыралар).* Безне атмагыз... Без белмәдек... Без мобилизованныйлар...

Бу хәлне күргәч, җәмәгать тагын өстәлгә таба агыла. Әптерәш карт, яннарына ук килеп, башын сузып карый. Хәйри аны да, башкаларны да куа. Семеновтан башка тоткыннар хурлыктан көяләр, куырылалар.

А н д р е е в *(Емельяновка).* Боларны штабка озатыгыз!

Е м е л ь я н о в *(тотып торгыза да контор төбендәге солдатка илтеп тапшыра).* Боларны каравыл белән штабка озаттырырга!.. *(Шакиров, Иванов ишектән кереп китәләр).*

С е м е н о в *(каравылның тыюына карамастан, җиңел, нык басып, өстәл каршына һавалы кыяфәт белән килеп туктый. Андреевка каршы кулларын козырекка куеп).* Мин ватан каршында үз бурычымны үтәдем...

А н д р е е в *(бераз аптырап).* Сез кем?

С е м е н о в. Мин Кызыл Армиянең 13 нче полк командиры идем... Үземә тапшырылган кызыл банданы сезнең утыгыз астына кертеп бетерттем. Хәзер миңа ни кушасыз? *(Тоткыннарга, Гайнетдиновның җирдә яткан гәүдәсенә күрсәтеп).* Бу разбойниклар янында бер генә минут тору да минем намусыма авыр!.. Минем фамилиям Семенов. *(Өстәл тирәсендәге алгы сафлар бер-берсенә күрсәтеп шатланышалар).*

А н д р е е в *(бераз гына уйлап ала).* Семенов? Семенов? Сез Владимир

Николаевичмы? Сезнең лəкабегез – Капланмы?

Семенов *(башын ия).* Шулай, дөрес. Мин Владимир Николаевич Семенов, яшерен лəкабем[1] – Каплан.

Андреев *(торып кул бирə).* Бик яхшы, бик яхшы! Мин сезгə атлар бирдерəм. Сез, бер минут кичекмичə, штабка барыгыз! Сезне анда белəлəр, көтəлəр иде... Менə сезгə язу бирəм. *(Тиз генə яза, портфельдəн алып, мөһерен баса да Семеновка бирə).*

Семенов *(козырекка кул куеп исəнлəшə).* Рəхмəт, бик рəхмəт! *(Җиңел, нык басып атлап, контор ишегенə кереп китə).*

Андреев *(тоткыннарга күз йөртə, Емельяновка ишарə кыла).* «Туташны» алга чыгарыгыз!

Емельянов мөгаллимəне тотып алгарак чыгара; хатын-кыз арасыннан Гөлҗамал, Зəйния, Фəтхия карчык ни эшлəгəннəрен белмичə Камəргə таба кузгалалар. Хəйри аларны кире чигендерə; тегелəрнең һаман да алга таба омтылганын күргəч, улы Вəли белəн бер чувашны аларны тотып торырга куя; башкалар да, тынычсызланып, алга таба кузгалалар. Хəйри һаман куа.

Андреев *(туташка бик дикъкать белəн карый).* Сез кем? Ничек элəктегез?

Камəр *(сабыр, тыныч тавыш белəн).* Кем булыйм? Мин мөгаллимə. Өч ел балалар укыттым... Хəзер партиядəмен... Бүген төндə, чигеп барганда, сезнең бандаларыгызга элəктек... Күрəсез, эт урынына кыйнап, газаплап, монда китерделəр...

Əхтəм Банаев *(Камəрнең сүзе вакытында ук өстəл ашасыннан үрелеп, Андреевның колагына нидер əйтə, бусы ризалык белəн баш ия).* Камəр туташ, сез тирə-яктагы атаклы мөгаллимə, бик өметле милли мəгариф хадиме[2] идегез. Нинди гөнаһ шомлык белəн сез болай миллəткə хыянəт юлына кереп киттегез?

Камəр *(кинəт башын күтəрə, гасаби, ачулы тавыш белəн).* Атарга көчегез бар, лəкин минем вөҗданыма кагылырга сезнең һичбер төрле хакыгыз юк... *(Каты тавыш белəн).* Без түгел, сез үзегез – халык дошманы! Сез үзегез халыкка каршы иң зур хыянəтче!

Банаев. Димəк, сез фикерегездəн кайтмыйсыз?!

Камəр. Ул турыда сүз булырга да мөмкин түгел!

Андреев *(Емельяновка).* Камəр Якупованы читкə ал! *(Камəрне җирдə яткан Гайнетдинов гəүдəсе янына китерəлəр... Батырханга күрсəтеп).* Менə моны китер! *(Емельянов Батырханны алга чыгара. Зəйния якын килмəкче була, каравыл аны читкə этəрə).*

---

[1] *Лəкабем* – кушаматым.
[2] Хадиме – хезмəткəре.

Г а л и м о в *(аягүрә басып укый).* Батырхан Җафаров, каторгадан качкан кеше; 33 яшендә; крестьян; кызыл коммунарлар отрядының командиры.

Җәмәгать бер-берен таптап алга килә. Өстәл тирәсендәгеләр артык диккать белән тоткынга карыйлар, нидер сөйләшәләр.

А н д р е е в *(ачулы, җитди, дошман йөзе белән аякка баса).* Сез кем?

Б а т ы р х а н *(истиһза белән елмая).* Кем икәнемне әйттеләр бит! *(Өзеп, санап, һавалы, мәгърур тавыш белән).* Мин – Англия, Франция капиталы оештырган Мировой контрреволюциягә каршы сугышучы эшче-крестьян Кызыл Армиясенең бер солдатымын! Өч көн элек *(чехка күрсәтә төшеп)* яраландым... Бүген төндә, чигеп барганда тотылдык.

Банаев, Галимов, Аксак бояр, чех, Митри Степаныч үзара нидер тиз генә сөйләшеп алалар. Галимов Андреевның колагына нидер әйтә.

А н д р е е в *(кинәт урыныннан кузгала, усал күзләре белән Батырханга йотыла. Бер кулы белән кобурына тыгыла).* Шулаймы? Сез каторжник, кызыл разбойник, ата большевик Батырхан Җафаровмы? *(Емельяновка).* Уң якка чыгар бу собаканы! *(Солдатларга).* Тиз! Винтовкаларны кулга!

Җәмәгать гөж килә. Әптерәш, Насыйб, Ярми тоткын ягына таба кысылып үтәргә омтылалар. Солдатлар ашыгыч-ашыгыч мылтыкларын шытырдаталар. Берсе күккә атып җибәрә.

А н д р е е в *(кызу, ачудан шашып, кобурыннан наганын чыгара, үзе шул якка ташлана).* Ни торасыз, болваннар!

Б и б и з ә й н и я *(акырып елап, Батырханны барып кочаклый, өстери башлый).* Тимәгез, атмагыз!.. Ул минем өчен каторда булды... Ул изге кеше! Аңа атмагыз.

А н д р е е в *(аяк тибеп, бөтен мәйданны ярып кычкыра).* Ни карап торасыз! Алыгыз шул дивана хатынны! Бәйләгез үзен!

Б и б и з ә й н и я *(үзен өстерәп читкә чыгара башлаган Емельяновтан ычкынып, чәче-башы тузган хәлдә өстәлгә таба килергә омтыла).* Аңа тимәгез! Менә, мә, мине атыгыз!..

А к к ү з ә т ч е *(Андреев, ачудан* шашып, Батырханга атар өчен наганын суырып алып кулын сузганда, ашыгып, шашып, козырекка кулларын куйган хәлдә килеп керә дә кызу тавыш белән Андреевка).* Господин командир, Саранов отряды фронт ярып чыкты... Аның атлы ротасы хәзер бу авылны килеп баса!

А н д р е е в. Булмас, ялгандыр, сез үзебезнең отрядны ялгыш күргәнсездер.

Туп тавышы килә.

---

* 1921 елгы басмада: *..ачудан, каһәрдән шашып...*

К ү з ә т ч е. Дөрес! Господин командир! Хәзер килеп басалар!

Күзәтченең килеп чыгуы белән аптырап калган җәмәгать, бу соңгы сүзне ишеткәч, бөтенләй тәртипне югалта. Күзәтченең сүзе бетмәс борын йөгерү, качу башлана. Өстәл тирәсендәгеләр бер-берен таптап, урындыкларны да аударып, шау-шу белән качалар.

А н д р е е в *(качып, таралып барган халыкка).* Җәмәгать, җәмәгать, курыкмагыз!.. Бүген кич бу авылны яңадан алачакбыз*! (Бу шау-шулы качу вакытында каравылсыз калган тоткыннарга ташланып, үзе арты белән чигенеп качкан хәлдә өзлексез ата. Батырхан, мөгаллимә, кызу, кинәт кузгалышлар белән тайчанып, йөгерәләр, арттарак калган Шәнгәрәй Андреевның пулясыннан «Аһ! Аһ!» дип егыла. Камәр белән Батырхан каршы якка чыгып котылалар).*

Б а н а е в *(тәртип бозылып, җәмәгать качып бетеп барганда да, эшләпәсен, пенснесен тота-тота үзе йөгергән хәлдә, Андреев атуын дәвам иттергән вакытта).* Җәмәгать, тынычланыгыз!.. Тынычланыгыз!.. *(Сөйләнә-сөйләнә кача).*

Качу бетмәс борын ук бик еш туп ату, аңа кушылган залп, сугышчы гаскәр тавышы бик каты, бик якыннан ишетелә. Бер урынны гаскәрнең килеп алуы вакытындагы рәвеш була, шул хәлдә мәйдан бөтенләй буш; бер минут анда ауган өстәлләр белән Гайнетдиновның гәүдәсе кала. Шәңгәрәй, бик аз гына вакыт үлем алды газабы белән бөтәрләнеп яткач, җан бирә.

Ш ә й б ә к *(аклар качкан яктан – контор артыннан килеп чыга, үлекләрне карап).* Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун! Урыныгыз җәннәттә булсын, балалар! *(Дога кыла).*

Шуның артыннан ук бер агачка таянып, авыруына карамастан, кызулап Б а т ы р х а н, К а м ә р, ө ч а к с о л д а т килеп керәләр. Камәр белән Зәйния үлекләргә ташланалар. Исәнлегенә өмет юкмы дигән кебек, яңа гына җан биргән Шәнгәрәйнең кулларын, күкрәкләрен карыйлар. Ике үлекне дә иплиләр, аларга Шәйбәк бабай да килеп кушыла.

Б а т ы р х а н *(үлекләрне күрүгә, җан әрнегән тавыш белән артка борылып, кычкырып җибәрә).* Кайда безнекеләр? Тиз, тиз, бөтен авылны аякка бастырсыннар!.. Эләккәннәрне монда китерсеннәр!

Җ а м а л и килеп керә.

Ак солдатлар *(Батырханга).* Без аклардан сезнең якка калдык, безгә ни кушасыз?

Б а т ы р х а н *(кулларын кыса).* Шулаймы?.. Бик яхшы! Җамали абзый, менә бу солдат иптәшләрне ал да тегеләрнең калдыкларын тотып китер!

Җ а м а л и. Була, бик була. *(Солдатларны алып, йөгереп чыгып китә).* Мин бирермен аларга кирәген!!

Батырхан, хәлсезләнеп, өстәлгә таба килә; җирдә аклардан калган наганны күреп, тиз генә ала, төзеклеген карый да чалбар кесәсенә тыга, урындыкка утыра. Шәйбәк, Камәр, Зәйния аңа киләләр.

Зәйния *(күз яшьләрен сөртеп, иренә сыена).* Ходаем, бу нинди бәхет бу!! Син исән калдың бит! *(Елый).*

Камәр. Батырхан абый *(үлгәннәргә күрсәтеп),* әйтегез миңа, бу каннар өчен кем җавап бирәчәк?!

Батырхан. Борчылмагыз, Камәр иптәш, бу корбаннар әрәм китмәс!

Шәйбәк. Аллаһ тәгаләгә шөкер итегез, балалар... Күкрәкләрегезгә кадалган сөңгеләрдән исән калдыгыз бит... Җыясы ризыкларыгыз бетмәгән, балалар... *(Үлекләргә таба атлый).* Бу шәһитләрне өйләренә илтеп куйыйк әле. Мин арба китертш.

Артта ат туктату тавышы, кешеләр сөйләшкәне ишетелә.

Ике кызыл күзәтче *(баштанаяк кораллылар; килеп керүгә Батырханга таба баралар).* Сез кемнәр, иптәшләр?

Батырхан. Мин кызыл коммунарлар отрядының командирымын... Болар минем иптәшләрем... Кичә чигеп барганда чех бандасына эләктек. Сез Саранов иптәш отрядыннанмы? Саранов үзе моннан үтәчәкме?

Күзәтче. Хәзер килеп җитәчәк. Безнең атлы батальонны Саранов иптәш бүген үз командасында алып килде...

Камәр *(шат, мөлаем йөз белән күзәтчеләргә килеп, кулларын кыса).* Сезнең отрядның килеп җитә алуы бер могҗиза булды, иптәшләр... Күпме халык үлемнән котылды...

Шәйбәк. Тәкъдир, балалар, тәкъдир! Җыясы ризыкларыгыз бетмәгән!..

Тимеркәй *(шатланып килеп чыга. Мондагыларны күрүгә, күз яше аркылы көлеп, сикеренеп).* Их, агайлар!.. Батырхан абый! Мөгаллимә апа! Шәйбәк бабай! *(Иң элек Батырханга ташлана. Аннан соң Шәйбәк белән Камәрне барып кочаклый).*

Батырхан *(Тимеркәйне күрүгә, урыныннан ук кузгала башлый).* Бу синме, Тимерхан туган?! Үтереп ташлаганнар дип, сине бик кызганыштык без. Мөгаллимә апаң үзеннән, бездән бигрәк синең өчен кайгырды... Әзрәк балавыз да сыгып алды бугай...

Камәр *(Тимеркәйгә иркәләнеп).* Балавыз сыкмадым сыгуын... шулай да мин сине бик, бик кызгандым...

Тимеркәй. Әйтмәгез инде... Ничек котылуым үземә дә бер төш кебек кенә булды. Кичә төнлә тегеләр килеп, юлны кискәч тә, мин үземне үзем белмичә, агач арасына йөгердем... Аннан чокырга ташланып, үземне комга

күмдем... *(Үлекләрне күреп).* Бу нихәл тагын?.. *Тагы кан? Бичараларның күпме балалары калды!.. *(Бераз гына кызганулы, аптырау хәлендә торганнан соң, кинәт ныгый, ачуга бата).* Ярар, ярар! Яңадан кайткач, үзләренә дә бирермен мин кирәкләрен!.. *(Батырханга).* **Батырхан җизни, ахырдан без җиңәрбез бит? Җиңәрбез бит, җиңәрбез бит?!

Батырхан. Җиңәрбез, җиңәрбез... *(Арттан ат туктаткан тавыш килә; «ту-у... ту-у...» дип кычкыралар).*

Кызыл күзәтчеләрдән Сафин *(шул тавыш ягына таба бара, үрелеп карый).* А! Безнең команда да бар. Командир Саранов иптәш үзе дә килеп җитте... *(Тыштан: «Мә атны», – дигән тавыш ишетелә).*

Саранов *(килеп керә. Баштанаяк күн киемнән, фронт хәленчә кораллы, яшь карасу йөзле,*** үткен егет).* Сез кемнәр, иптәшләр?

Батырхан *(таягына таянып, урыныннан тора).* Сез мине беләсездер... Минем отрядым сезнең белән янәшә сугышты... Мин – Батырхан Җафаров!

Саранов. А, менә нинди көтелмәгән очрашу! *(Килеп кулын кыса).* Сезне күрүгә мин бик, бик шатмын... Исемегез бу фронтта бик яңгырады...

Батырхан. Сүзгә каршы сүз: күршемдә сезнеке кебек бер гайрәтле отрядның булуы минем өчен бик зур бәхет иде.

Саранов *(якын ук килеп, яңакларын карый).* Яраларыгыз бик куркыныч түгелме? Сезгә мин бераз эш йөклим.

Батырхан. Юк, куркырлык яра юк.

Саранов. Алайса менә нәрсә, иптәш! Хәзер озаклап сөйләшергә вакыт юк. Мин сезгә үземнең отрядымнан егерме кеше калдырам. Отряд исеменнән бөтен властьны сезгә тапшырам. Нәрсә кирәк, шуны эшләгез дә бүген кич Таштамакта[19+] булыгыз. Үзегез туры миңа төшегез... Хушыгыз! *(Яңадан кул бирә, башкаларга баш ия).* Положениене беләсез... Кичегергә бер дә ярамый...

Батырхан. Ярый, хушыгыз!

Саранов *(күзәтчеләрнең беренә).* Сафин иптәш, син үз взводыңнан егерме кеше белән Батырхан иптәш кулына каласың! Аңладыңмы? *(Китә).*

Сафин. Ярый, аңладым.

Әптерәш, Ярми, Насыйб, алар артыннан кызылармеецлар килеп керә.

Әптерәш *(Батырханга ике кулын сузып килә).* Син, туган, исән калгансың икән...

---

* 1921 елгы басмада: *Илаһым, тагы кан?*

**1921 елгы басмада: *Батырхан җизни, Троцкий "ахырдан без җиңәрбез" дигән бит?*

*** 1921 елгы басмада: *..усал карашлы..* сүзләре бар.

Б а т ы р х а н . Шулай, бабай, гомер бар икән әле...

Ә п т е р ә ш үлекләргә бара, аптырап, хәйран булып карап тора.

Н а с ы й б . Батырхан абзый, калсак, безне терелэй тунарлар. Мин синең белән китәм.

Я р м и . Мин дә синнән калмыйм. Аксак боярлардан издерер хәл юк монда. Бу этләрдән талатканчы, сугышта * үләрмен. *(Үлекләргә күрсәтеп).* **Ничаклы балалары ятим калды!

Б а т ы р х а н *(егетләрнең кулларын кыса).* Яхшы, бик яхшы, туганнар!.. *(Тимеркәйгә).* Тимеркәй, мин сиңа биш красноармеец иптәш бирәм. Тиз генә кит тә авылдан попны, мулланы, Аксак боярны, Хәйри кулакны, Кәҗә Якупны эзләп монда китер. *(Мөгаллимәгә).* Ә сез, Камәр иптәш, Зәйния белән безнең өйгә барып, тиз-тиз юынып, төзәтенеп килегез, вакыт тар, тиз йөрегез... *(Һәммәсе китәләр, Шәйбәк бабай да китә. Калганнарга).* Иптәшләр, менә бу үлекләрне*** өйләренә кайтарырга кирәк...

Сафин взводыннан калган кызылармеецлар үлекләрне күтәрәләр. Әптерәш карт, Насыйб, Ярми аларга булыша. Батырхан да ярдәмләшә. Күтәргәч, Сафин башлый, бүтәннәр кушыла: авыр, басынкы көй белән «Бәхилләшү» («Похоронный марш») җырлаган хәлдә күтәреп алып чыгып китәләр... Берәр минут үтүгә контор артыннан тавышлана башлыйлар... Кемнедер кыйнап, шаулашып алып килгәнлек тавышы ишетелә.

Ул арада погоннары ертылган, башы тузган, йөзе яраланган Г а л и м о в белән чәче-сакалы пумала кебек тузган яланбаш А к с а к б о я р н ы крәстиәннәр кыйнап китереп кертәләр.

Җ а м а л и (*алдан йөгереп керә. Тоткыннарны өстерәп, аның белән тагын биш ярлы крәстиән керә. Бер кеше дә күренмәгәч, кычкыра).* Батырхан, Батырхан, син кайда?!

Б а т ы р х а н *(таянган хәлдә ашыгып килеп керә).* А!.. Бу каһарманнар эләккән икән!..

Җ а м а л и *(ашыгып, кычкырып сөйли).* Батырхан туган, син ачуланма инде... йөрәк түзмәде. Эләккәч бераз биргәләп алдык.

Б а т ы р х а н *(тоткыннарга каһәр белән карый).* Кайда тоттыгыз бу явызларны?

Җ а м а л и *(крәстиәннәргә күрсәтеп).* Менә болар урманда утын кисәләр икән. Аклар авылдан кача башлагач *(кулы белән күрсәтә),* Аксак боярның аты дулаган да бу ике дуңгызны чокырга ташлаган. Башкалар качкан. Боларны менә безнең авыллар тотып китергәннәр.

---

* 1921 елгы басмада: *шәһит булып* сүзләре килә.

** 1921 елгы басмада: *Ходаем, ничаклы балалары ятим калды.*

*** 1921 елгы басмада: *шәһитләрне.*

Башка крәстияннәр *(берьюлы).* Шулай, Батырхан, шулай!

Батырхан. Яраган, бик яраган. *(Тоткыннарның каршына килә, йөзе тимерләнә, күзләренә ачу чыга).* Сезме эшче-крәстиән палачлары? *(Наганын чыгара; крәстиәннәр читкә тая; Батырхан рәттән дүрт мәртәбә ата: Галимов, Аксак бояр йөзтүбән капланалар. Батырхан, хәлсезләнеп, билен тотып, өстәлгә килеп ава).*

Тимеркәй *(ике солдат белән чалма-чапаннан беренче мулланы кертә).* Батырхан җизни, менә берсе капты, бүтәннәрен хәзер эзләргә китәм. *(Чыгып китә).*

Төенчек тотып Шәйбәк карт килеп керә. Бер муллага, бер Батырханга аптырап карап тора.*

Мулла *(агарынган. Сүзләрен бүлә-бүлә).* Батырхан туган, без инде имам кеше буламыз. Мәэмүрләр[1], ягъни мәсәлән, өлеләмер[2] кушкач, чехларга да барган идек... Без үземез алай бәлшәүниккә[3] каршы түгел, ягъни мәсәлән, итагать итәмез...

Батырхан *(ачуланып, каһәрләнеп).* Бу нинди эш инде! Чехка да, советка да итагать! *(Кызып, наганны кулына ала да муллага таба ташлана).*

Шәйбәк *(Батырханның сузган кулына барып асыла, көч белән туктата).* Юк, юк, Батырхан, син кул салма... Ул минем сүземне тыңлар. Безгә зарар итмәс...

Батырхан *(бераз тынычланып).* Зарар итмәссеңме? Эшче-крәстиәнне үтертергә фатиха биреп йөрмәссеңме?

Мулла *(каушап, калтырап).* Итмәм... Зарар итмәм... Эшче-крәстиәнне үтертергә фатиха бирмәм... бирмәм...

Батырхан *(йөзен, кашын җыера, җирәнеп, муллага).* Ярар, менә бу карт *(Шәйбәккә күрсәтә)* хөрмәтенә мин сине калдырам... Бар, чык!

Мулла. Рәхмәт, туган, рәхмәт! Алла үзеңә исәнлек бирсен. *(Чыгып китә.)*

Батырхан *(үзалдына).* Бу гадиналарга пуля әрәм... Безгә дә итагать! Чехка да итагать! Тфү!.. *(Төкеренә, хәлсезләнеп, урындыкка килеп ава.)*

Шәйбәк *(Аксак бояр белән Галимовның үлек гәүдәсен күреп, аптырап кала, Батырханга килә).* Әй, туган! Син тагы кан түккәнсең икән! Ярамас, бер дә ярамас иде!

Батырхан. Их, бабай, ни эшлик, ни генә эшлик?! Син үзең дә беләсең

---

* 1921 елгы басмада: *Батырхан (шелтә белән). Сезгә ни калган инде ул халык дошманнары белән йөрергә?*

[1] *Мәэмүрләр* – кушкан эшне үтәүчеләр.

[2] *Өлеләмер* – түрәләр.

[3] *Бәлшәүниккә* – большевикка.

бит, зарарлы чүпне утап ташламасаң, ул бөтен җирне каплап, ашлыкны харап итә!.. *(Авыр хәлдә торып, бабайның кулына тотына).* Җан кыю безгә дә уен түгел, бабай... Теге вакытта, Саткайны үтергәннән соң, мин кан күрә алмый торган булдым... Адәм түгел, малга да пычак тидерә алмый идем... Туры килеп, кызулык белән бер офицерны аттым: шуннан соң төн йокыларым качты. Ашаган ашымнан, эчкән суымнан адәм каны исе килә торган булды. Шашып калдым... *(Эчке дулкын белән йөренә башлый).* Бу эшләрне ташлап, урманга, тауга качарга уйладым. Шул арада контр-революционерлар бер җирдә бунт чыгардылар. Ике сәгать эчендә безнең утыз иптәшебезне газаплап, авыз-борыннарын кискәләп киттеләр... Бу корбаннарны күргәч, мин яңадан ныгыдым... *(Өстәлгә килеп, Әхтәм Банаев утырган җиргә кулы белән каты суга).* Бая ишеткәнсеңдер, менә шул җирдә капитал ялчысы Әхтәм Банаев нәрсә диде? Хәтереңдәме? Ул бөтен дөнья алдында: «Без чехсловакларның канлы штыклары аркасында азатлык алдык», – дип игълан кылды. Буржуйлар әнә шулай карый, бабай... Безгә дә, безнең эшче-крәстиән халкына да контрреволюционерларның башлары өстеннән азатлыкка барырга туры килә... Башка юл юк... Юк, бабай... *(Картның кулыннан тотып, контрларның үлек гәүдәсенә китерә. Кулы белән күрсәтә. Ачык, кискен тавыш белән).* Юл бер генә! Менә шушы канлы юл – изге юл!

Шәйбәк. Белмим, балам, белмим, күп кан түгүдән саклан! Чүпне утыйм дип, ашлыкны әрәм итә күрмә.

Мөгаллимә *(юынып, йөзендәге яраларын бәйләп килеп керә. Башында шәл, өстендә хатыннарча тектерелгән соры шинель, кулында төенчек).* Менә без килеп тә җиттек!.. *(Үлекләрне күреп).* Ах, тагын кан! Ни эшлик?! Ни генә эшлик? Башка юл юк, юк, юк шул!

Зәйния *(Камәрнең артыннан ук килеп җитә. Niлердер күтәргән. Авыр уйланып иренә килә).* Ходаем, мин тагын каламмыни инде?

Батырхан. Елама, Зәйния, без тиз кайтырбыз... *(Авыр кузгалып, тышка таба барып кычкыра).* Иптәшләр, кире кайтыгыз!.. Китәргә вакыт! *(Зәйниягә).* Акыллым, менә шуны әзрәк төзәт әле. *(Яңакларын ипләтә).*

Тимеркәй. Китәбез дәмени?! Ах, теге дуңгызлар әрәм калдылар бит! Кәҗә Якуп белән Карун Вәлине үз кулым белән бетерермен дигән идем.

Ярми. Батырхан абзый, алты олау килде, шул җитәме?

Батырхан. Җитә, бик җитә!

Шәйбәк *(китүчеләргә).* Хәерле юл, балалар, Алла сезгә исәнлек бирсен! *(Кулындагы әйберләрен Тимеркәйгә бирә).* Менә бу сезгә карчыгымнан юл-аяклык.

Батырхан *(картка якын килеп, кулбашыннан ала).* Шәһибәк бабай, сине харап итәрләр бит монда калсаң, ник безнең белән китмисең?

Ш ә й б ә к *(сабыр, эчке акрын тавыш белән).* Үтерсәләр, үлем бер, балалар... Тәкъдирдән уза алмаслар әле. Мин инде карт кеше: анда китеп тә сезгә йөк кенә булырмын. Гомер булып, исән калсам, монда минем кирәгем булыр әле.

Б а т ы р х а н *(бабайның кулларын кыса).* Синең исәнлегең безнең өчен бик кирәк, бабай. *(Читкә алып, колагына нидер әйтә, Шәйбәк ярар дигәнне аңлатып баш ия).*

Н а с ы й б *(тыштагы ат-арба тавышына кинәт борыла... Андагы олаучыларга).* Әптери, әйбер таптатасың, күк биянне уңгарак ал!

М ө г а л л и м ә *(шат йөз белән елмаеп, бабайга кул бирә).* Шаһибәк бабай, синнән бер үтенеч: Карамалыда минем ятим карчык әнкәй бар. Шуңа бер юл уңаенда кереп чыгып, сәламемне әйт! Үзен бераз юат!

Б а т ы р х а н . Бабай, син минем Зәйниямне дә онытма.

Ш ә й б ә к . Ярар, балалар, ярар... Без монда сезнең кайтуны бергәләп көтәрбез. *(Камәргә).* Әнкәңне беләм. Иртәгә үк барырмын...

К а м ә р *(Зәйниягә килә).* Кайгырма, елама, Зәйния апа... *(Ярым кочаклап).* Без бит гомергә китмибез... Бу сугышлар бетәр. Матур, рәхәт көннәр килер... *(Үбешеп күрешәләр).*

Туп тавышы якыная.

Ә п т е р ә ш *(ашыгып килеп керә).* Батырхан туган, «тегеләр» якын ди бит... Сезгә тимәсләрме?..

С а ф и н *(шунда ук үзенең взводы белән килеп керә).* Батырхан иптәш, положениене беләсең. Безгә ашыгырга вакыт. *(Артында егермеләп солдаты тора).*

Б а т ы р х а н . Иптәшләр, сез әзерме?.. *(Солдатларның берсе Батырханга фуражка, шинель бирә, киендерәләр).* Әйдәгез, кузгалабыз! *(Контор артына чыгып китәләр, Батырханны бераз култыклап баралар).*

Т ы ш т а н Т и м е р к ә й т а в ы ш ы . Зәйния апа, Шәйбәк бабай, сау булыгыз!.. Буржуйларга бирешмәгез!.. Кайгырмагыз, без тиз кайтырбыз!..

Ат каулау, озату шау-шуы ишетелә; сәхнә аз гына вакыт буш кала. Ә п т е р ә ш , З ә й н и я белән Ш ә й б ә к авыр, салмак атлап сәхнәдән үтәләр. Зәйния елый.

Ш ә й б ә к *(Зәйнияне юата, иркәли).* Елама, балам, елама... Алар тиз кайтырлар...

Пәрдә төшә.

**ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ**

К А Т Н А Ш У Ч Ы Л А Р

Б а т ы р х а н – N нче кызыл коммунарлар полкының командиры. Аягы

бераз аксый, маңгаенда, яңагында бик тирән яралар. Элекке пәрдәдәгеләргә караганда бераз картайган. Баштанаяк фронт хәлендә, күн киемдә.

Тимеркәй – Батырхан полкында бер рота командиры; бөтенләй кызыл командирлар киемендә.*

Фәтхия – күп картайган, ватылган, баштанаяк ак киемдә.

Гөлжамал – мәрхүм Шәнгәрәйнең хатыны; елак, гасаби[1]; үзе дә, балалары да бик артык ярлы киемдә.

Зәйния – бу пәрдәдә төзәлгән, чибәрләнгән; ачык, сәламәт табигатьле.

Әхтәм Банаев – бөтенләй икенче пәрдәдәгечә; кулында жәйге пальто белән зонтик.

Әптерәш карт – алтмыш яшьләрендә; нечкә, ябык, ач яңак; ияк очында аз гына сакалы бар; бите бик эре җыерчыклы.*

Кәрим – авыл советы рәисе, ярым гаскәри киемдә, оек-чабатадан.

Насый кызылармеецлар, йөрешләрендә, торышларында

б} хәрби сыйфат нык сизелә.

Ярми}

Җамали – икенче пәрдәдәгечә. Кулында зур тимер лом.

Үтерүчеләр – авыл байларының уллары. Яшьләре 25-30 ларда; кызыл йөзле, таза егетләр. Өс-башлары авылча яхшы.

Авыл ярлылары, хатын-кыз, бала-чага.

Хәйри байның өе, ләкин беренче пәрдәдәгегә караганда бик күп дәрәҗәдә ярлыланган. Стена буенда [20+] бер юл чемоданы, одеал, мендәр чишелмәгән хәлдә торалар. Тәрәзә төбендә кечкенә лампа яна.

Пәрдә ачылганда Фәтхия әби идәндә намазлык өстендә ясту укый, “Әттәхият”тә [21+] утыра.

Гөлҗамал, җиде-сигез яшьлек ике баласын ияртеп, ачык, шат йөз белән килеп керә дә, карчыкның намаз укыганын күргәч, ишек төбендә сүзсез-нисез туктала; эчкә таба үтәргә теләгән балаларын туктата.

Фәтхия *(як-ягына сәлам биргәндә, Гөлҗамалны күрә дә кул күтәреп дога кыла, кулында тәсбихе булганы хәлдә тора)* Иляһем, хуҗам, тынычлык бир, балаларга исәнлек бир... *(Гөлҗамалга).* Нихәлең бар, Гөлҗамал килен?

Гөлҗамал *(кулындагы кызылсу төстә ситсыны күтәреп, шат тавыш белән).* Әбекәем, әбекәем... чыдамадым, шатлыгымнан сиңа йөгердем. Батырханга да рәхмәт әйтим дидем. Кара, әбекәй, мина ничаклы нәрсә

---

* 1921 елгы басмада бу җөмлә бар: *Үзендә, бөтен торышында җитди, кискен хәрби төс.*

[1] *Гасаби* – нервлы.

* 1921 елгы басмада шулай ук:*...Хәйри байда егерме елдан артык ялчылыкта торган. Ул беренче, икенче пәрдәләрдә шул ук рәвештә.*

бирделәр бит... *(Ситсыларны туздырып ташлый, карыйлар).*

Ф ә т х и я. Гөлҗамал килен, каян сиңа бу чаклы байлык?

Г ө л җ а м а л. Әйтмә инде, әбекәем. Миңа да бирделәр, мәрхүм Шәйбәк бабай карчыгы Сәрби әбигә дә бирделәр.

Ф ә т х и я. Рәхмәт төшкерләре! Үзләре белән алып килделәрме икәнни боларны? Төсе дә чибәр, ныклыгы да бар.

Г ө л җ а м а л. Юк, әбекәй, юк. Кызылларның килгәненә атна да юк бит әле... Җәһәннәм кебек ут арасында ничек әйбер китерә алсыннар, ди. Безнекеләрне үтереп Себергә качкан теге явызлар бар бит. Шуларның калган малларын алып патрибикәгә китергәннәр икән. Шуны безгә өләштеләр. Биргән вакытта Тимеркәй үзе карап торды. Рәхмәт инде, Тимеркәй туган, дигән идем, юк, җиңги, ди, боларны мин бирмим, Совет бирә, мина түгел, Советка рәхмәт әйт, ди. Болар болай гына бирү әле, ди. Менә акларны бетереп, сугышлар тукталгач, Совет сезне байлыкка күмәр, ди. Бу Тимеркәйне әйтәм, әбекәй, бөтенләй, бөтенләй икенче кеше булып кайткан. Хәзер ул укырга-язарга да өйрәнгән, ди.

Ф ә т х и я *(ситсының аршын исәбен саный).* Егерме аршын икән, килен. Үзенә дә, балаларыңа да берәр катка иркен җитәр.

Г ө л җ а м а л. Җитә, бик иркен җитә.

Ф ә т х и я. Алла кабул итсен инде, килен. Түккән күз яшьләреӊ өчен булсын. *(Шкафтан икмәк кисәкләре, ике йомырка алып, балаларга бирә).* Мәгез, сез ачтырсыз, бичаракайлар... *(Балалар йомырканы карыйлар, икмәкне кимерә башлыйлар).*

Г ө л җ а м а л. Сөйләмә инде, әби... Бер дә гөнаһсызга аттылар, Шәнгәрәйне үтерделәр... *(Елый).* Шуннан соң менә бер ел буенча балаларым белән ач-ялангач тордым... Мин күргәнне бәхетле кешенең эте дә күрмәс...

Ф ә т х и я. Елама, килен... Алла җан биргәнгә җүн бирер әле. Ирең Шәнгәрәй мәрхүм кызыллар кешесе иде бит. Сине ач итмәсләр, карарлар...

Г ө л җ а м а л. Аллага шөкер инде, әби... Әле бит миңа ашарга да бирәләр... Ике пот[1] он, чәй, ярма язганнар. *(Шатланып).* Бер уйласаң, гаҗәп инде бу эшләр, әбекәй. *(Өзеп, санап әйтә).* Үткән ел бичара бәлшәүникләр, дөньяларын ташлап, алга-артка карамый качканнар иде. Ә быел кызыллар үзләре теге акларны эштән чыгарып куалар. Әбекәй, бу кызыллар бөтен дөньяны алып бетерәләр, ди, бит.

Ф ә т х и я. Белмим инде, килен. Ни генә булса да, хәерлегә булсын инде.

*З ә й н и я (бер кулына чүмеч, берсенә пычак тотып килеп керә. Яулыгы*

---

[1] *Пот* – 16,3 кг тигез авырлык үлчәве.

*артка кайтарып бәйләнгән, җиңнәре сызганган, үзе эш өендә, ут алдында нидер хәзерләгән, пешеренгән кебек янып кызарган. Ишектән үк сукраныып керә).* Ходаем, бөтен кирәк-яракны алып китеп бетергәннәр. Нәрсәгә тотынсаң, шул юк. Әнкәй, безнең зур таба белән челтәрле чүмеч кайда икән? *(Гөлҗамалга).* Нихәл, Гөлҗамал җиңги? *(Әйберләрен күреп).* Бу ни бу?

Гөлҗамал. Ни булсын инде, Зәйния кайнигәч, бүген ятим җирнең бәйрәме бит! Барыбызны да киендерделәр. Ашарга да бирделәр. Мин дә алдым. Теге аклар үтергән Шәйбәк бабай карчыгы Сәрби әби дә, мәрхүм тимерче катыны, көтүче Сафи әнкәсе дә алды...

Зәйния *(әйберләрне караган хәлдә).* Бик, бик яраган инде. Сине кызганып, минем елыйсыларым килә иде.

Гөлҗамал *(Зәйниягә сөеп карый).* Зәйниякәем, ул вакытта син үзең дә кайгыдан кипкән, саргайган идең. Хәзер кем булдың: тазардың, чибәрләндең. Алла тәгалә яңадан ул көннәрне кайтармасын инде... *(Күз яшен сөртә).*

Зәйния. Юк, җиңги, ул кара көннәр яңадан кайтмасын инде... Минем Батырханым әйтә: Совет, ди, бервакыт бөтен дөньяны алып бетәчәк, ди.

Гөлҗамал. Шулай булсын иде инде!

Зәйния *(Фәтхиягә).* Әнкәй, бу нихәл инде бу? Ташландык йорт кебек калганбыз. Юлга ашамлык хәзерләмәкче идем. Нигә тотынсаң, шул юк. Челтәрле чүмеч белән зур табаны да алып киттеләрмени?

Фәтхия. Ни эшлим соң, балам. Көндәшем Зөһрә, аклар китә башлагач, көн җыенды, төн җыенды. Бер атна җыенды да алты йөк нәрсә төяп китте...

Гөлҗамал *(өйгә күз йөртә).* Әйтәм, сезнең өй ташландык оя кебек калган. Шул икән... Сандык та юк, шкаф та буш. Сәгать, көзге дә калмаган. Шул төядемени?

Фәтхия. Шул төяде шул. Ирем Хәйри миңа да бик әйтте. Монда калсаң, көн булмас, ди. Кызыллар, ди, мулла-мәзинне асалар, мәчетне азбар ясыйлар, хатын-кызны уртак итәләр, китап-Коръәнне утка ягалар, ди.

Әптерәш *(трубкасын тотып килеп керә).* Исәнме, Гөлҗамал килен! *(Мич алдына барып, көлдән утлы күмер актарып чыгара да, яндырып, морҗага тарта башлый).*

Гөлҗамал. Үзең бик исәнме, Әптерәш бабай?

Әптерәш. Фәтхия тутай, мин үзем дә аңа хәйран калдым... Хәйри байны әйтәм, ничек ул сине үзе белән Себергә алып китмәде?

Зәйния. Әнкәй бик аптыраган иде. Бер китәргә дә уйлады да, мин җибәрмәдем: нәрсә бар анда аңа, карчык кешегә? *(Әптерәшкә).* Әмма менә син китмәгәнгә эткәйнең ачуы килде дә инде... Бер дә харап!

Әптерәш. Әйтмә инде, Зәйния, аклар кача башлагач, минем башымны әйләндереп бетерде ул.

Гөлҗамал. Әптерәш бабай, син бит байга ярау белән мактаулы ялчы идең. Хәйри бай: минем Әптерәш авылда бер генә, дип мактана торган иде. Ничек калгансың?

Зәйния *(урыныннан тора).* Сүз бозау имезә, диләр. Минем анда күмәчләрем көймәсен тагы! *(Көлә, ашыгыч чыгып китә).*

Әптерәш *(трубкасын авызыннан ала).* Әйтмә инде, Гөлҗамал килен. Мин китми калуыма үзем дә кайбер вакыт аптырап китәм... Элек, байның фатихасы дип, кот оча иде. Хәзер инде ничектер күңел үзгәрде; бик кыстап та бармагач, Хәйри бай мине каһәрләргә тотынды: алты йөк нәрсә алып китәм, ди. Син бергә булсаң, юлда минем җаным тыныч булыр иде, ди. Юк, мин әйтәм, булмас инде, иректе көннән Себергә бармам, дим. Мин, ди, сине егерме ел асрадым, ди. Шулай дигәч, ачуым кайнап китте. Шәп, мин әйтәм, асрадың. Син мине түгел, мин, дим, сине асрадым. Менә синең бу йортларыңда минем көчем, каным катнашкан, дим. Шулай дигәч, баем кызып китте... Чү, ахмак, ди. Әллә син, ди, карт көнеңдә бәлшәүник булдыңмы, ди. Юк, мин әйтәм, Алла сакласын андый эштән, дим. Шулай да бу йортларга минем көчем, каным кергән, минем хакым бар, дим. Элгәре, мин әйтәм, Себергә разбойникларны җибәрәләр иде, дим. Синең дә, мин әйтәм, гөнаһың зур, күрәсең, дим. Булмаса, дим, үз иркең белән Себергә китмәс идең, дим. Әйт әле, мин әйтәм, бу нихәл? Аклар, дим, бичара Шәнгәрәйне, тимерчене, әүлия карт Шәйбәкне үтерделәр, дим. Кызыллардан, мин әйтәм, син качасың, Митри Стипаныч кача... мулла кача... поп кача, дим... Теге Аксак бояр марҗасы да, ун йөккә әйбер төяп, сызган, дим. Әллә, мин әйтәм, сезгә монда җир тарайдымы, дим. Баем кызарды, бүртенде... Тарайды шул, тарайды, ди. Менә яңадан кайткач, берьюлы киңәйтербез әле, ди. Үзе акыллы баш бит: алты йөк төяп, барлык хәзинәне алып китте. Алырлык булмаганнарын сакларга дип, улы Вәлине калдырды. Байның башы эшли аның...

Насыйб *(Шәйбәк картның таягын, бохар кәләпүшен, камзулын, аркан, чабаталарын, бик иске чапанын күтәреп килеп керә, Фәтхия әбигә).* Фәтхия әби, менә болар мәрхүм Шәйбәк бабайның әйберләре. Аның карчыгының өе җимерелгән. Башка торыр җире булмагач, Батырхан абый аны бу йортка күчерергә кушты. Сәрби әби үзе иртәгә килә. *(Әйберләрне бирә дә чыгып китә).*

Фәтхия. Ярар, балам, ярар. Өйләребез зур, сыярбыз әле. Ул бичара карчык та ахыр гомерендә ялгыз калды шул. Китер, менә монда куй. *(Әйберләрне ала. Гөлҗамал, Әптерәш берәм-берәм тотып карыйлар).*

Әптерәш. Әүлия бер карт иде, бичара... *(Арканын, чабаталарын*

*карап).* Мәрхүмең башлаган чабаталарын да тугып бетерә алмаган бит.

Зәйния *(килеп керә. Әйберләрне күрүгә бераз аптырап килеп тота).* Болар ниләр?

Гөлҗамал. Мәрхүм Шәйбәк бабай нәрсәләре... Аның карчыгы сезгә күчә икән.

Зәйния. Әнкәй, шулаймыни?

Фәтхия. Әле генә Насыйб кереп чыкты. Карчыкның өе җимерелгән икән, Батырхан кияү аны безгә күчерергә кушкан.

Зәйния. Күчсен, әнкәй, күчсен! *(Таяк белән кәләпүшне, чалманы уртагарак чыгарып карый).* Бичара бер әүлия карт иде. Әрәм генә иттеләр бит. Ишеткәч, акылымнан шаша яздым.

Гөлҗамал. Сөйләмә инде, Зәйния. Ул мәрхүм Шәйбәк бабайның яхшылыктан башка бер эше дә юк иде бит. Нигә генә үтерделәр икән ул әүлия картны... *(Күзен сөртә).* Мәрхүмгә кәфен юк, җеназа юк, эт үләксәсе кебек бер чокырга ташлаганнар да өстенә туфрак сибеп киткәннәр... Сәрби әби әйтә, хәзрәттән күз яше белән елап сорадым, ди. Мөселман зыяратын пычратыр хәлем юк дип әйтте, ди.

Әптерәш. Ярый инде, Батырхан туган кайткач, картны бик олылап, ялгызын тау башына күмделәр, ичмасам... Аллаһ тәгалә туфрагын җиңел итсен инде.

Гөлҗамал. Ишеткәч, мин дә хәйран булдым. Нигә генә үтерделәр инде аны?

Зәйния *(әйберләрне рәтләп, бер урындыкка куеп бетә).* Нигә була димени, Гөлҗамал җиңги?! Ул бит, карт булса да, кызыллар яклы иде. Безнекеләр киткәч, һаман астыртын аларга эшләп йөргән.

Гөлҗамал. Ул нәрсә эшли алган икән, мәрхүмең?

Зәйния. Минем Батырханым сөйләп бетерә алмый аны! Шәйбәк бабай – безнең өчен алтын иде, ди. Ул мәрхүм арбасына бер-ике чабата белән берничә аркан сала икән дә, аларның астына Советның китапларын, акларга каршы язылган кәгазьләрен төяп, базардан базарга таратып йөри икән... Аклар кача башлагач, безнең тирә-як никрутлары бит урманнарда качып ятты, Шәйбәк бабай шуларга халыктан азык җыеп илтә икән... Менә шулай йөргәндә, аны төнлә теге югары оч байлары урманда үтереп ташлаганнар. Мин сөйли белмим... Тагы әллә ниләр, әллә ниләр булган инде. *(Шкафтан бер агач табак барып ала, ишеккә таба атлый).*

Гөлҗамал. Әйтәм, аны кызыллар бик зурлап күмделәр, шулай икән ул! Каберенә бөтен авыл барды бит. Әллә ничаклы солдат та килде, ди. Батырхан кайнем, мәрхүм Шәйбәк бабайны мактап, шундый сөйләде, шундый сөйләде, ди... еламаган кеше калмады, ди.

Т ә р ә з ә д ә н   б е р е н ч е   т а в ы ш. Кызыл коммунарлар мондамы?

И к е н ч е   т а в ы ш *(көлеп)*. Тиле, кызыл коммунарлар димә: кызыл коммунарлар командиры Батырхан абзый диң!

Ә п т е р ә ш *(тәрәзәгә килеп, пәрдәне ача)*. Кем бар анда, ни кирәк?

Б е р е н ч е   т а в ы ш *(ашыгып)*. Батырхан абзый кирәк иде. Анда мөгаллимә апаны үтереп ташлаганнар, диләр.

З ә й н и я *(моны ишетүгә яшен суккан кебек катып кала. Кулындагы табагын төшереп җибәрә)*. Күңелем нидер сизенә иде... Камәркәемне дә бетерделәр, күрәсең. *(Караваттагы калын шәлне ала)*. Батырхан кайда соң? *(Йөгереп чыгып китә.)*

Г ө л җ а м а л *(йөгереп тәрәзәгә килә)*. Иплэп сөйләгез... Чынмы икән?.. Безне юкка куркытмыйсызмы?

Б е р е н ч е   т а в ы ш *(тәрәзәдән)*. Чын, ди, чын, ди. Гәүдәсен алып кайталар, ди. Үтерүчеләрне тотканнар, ди... *(Китәләр)*.

Б а т ы р х а н белән З ә й н и я килеп керәләр. Өйдәгеләр әйтәсе сүзләрен әйтә алмый катып калалар.

Б а т ы р х а н *(нык, таза, ашыгыч атлап килеп керә. Кулында хәрби харита, бер кәгазь, карандаш, пакет. Һичкемгә һичнәрсә әйтмичә, туры караватка таба килә, кулындагыларын ташлый, каешларны, кобурны алып, тиз-тиз киенә, Зәйниягә)*. Син эшеңдә бул! Мин хәзер кайтырмын, безгә ашыгыч китәргә туры килмәсен! *(Ашыгып чыгып китә, Зәйния хыялына югалып катып кала.)*

Ф ә т х и я. Әй, бичара бала, бала!.. Аны да әрәм иттеләр, күрәсең! Кичә генә кайткан иде... *(Чемоданнар янына килеп.)* Менә бит әйберләре дә чишелмәгән...

Г ө л җ а м а л *(күзләрен сөртә)*. Сөйләмә инде, әбекәем!.. Барлык яхшы кешеләребезне үтереп бетерәләр, күрәсең! Ул мәрхүмкәй кайтса-килсә: нихәлең бар, Гөлҗамал җиңги, дип, өзелеп тора торган иде. Бервакыт шулай авыру күзләрем белән яманып утыра идем. Мәрхүмкәем килеп керде дә, кая әле җиңги, үзем ямап бирим, ди. Алды да койган кебек ясап бирде...

З ә й н и я *(Камәрнең әйберләре янына килә, хыялына югалган хәлдә, гүя үзалдына сөйләнә)*. Шәнгәрәй абзыйны аттылар... Тимерче Габдулланың күпме баласын ятим калдырдылар... Әүлия карт Шәйбәк бабайны үтереп ташладылар... Инде Камәр дә юк! Бу нинди эш бу?

Т и м е р к ә й *(ачудан шашып килеп керә. Аякта яхшы итек, галифе чалбар, башта күн фуражка. Җиңел, төз атлап, шкафка килә дә ашыгыч кул белән кобурын, юл дәфтәрен, күн тәмәке савытларын алып китә башлый)*. Зәйния апа, бер генә минутка чык әле. Анда сине чакыралар. *(Зәйния сүзсез, ашыгып чыгып китә)*.

Ф ә т х и я , Г ө л җ а м а л *(берьюлы Тимеркәйгә).* Ни бар? Мөгаллимәнең хәле ничек?

Т и м е р к ә й *(киенүен дәвам иттергән хәлдә).* Ни генә булсын! Ни генә булсын! *(Әрнеп).* Бүген кич Кызылтамактан, собраниедән кайтып килә икән... Урманда саклап торганнар да, үтереп, гәүдәсен чокырга ташлаганнар... Олаучының кулын-аягын бәйләп, авызын каплап киткәннәр.

Г ө л җ а м а л *(коты очып, шашып).* Кемнәр, ди? Тотылганнармы?

Т и м е р к ә й . Кем булсын?! Шәйбәк бабайны кемнәр үтерде? Болар да шул югары оч байлары инде! Безнең кешеләр тауда таш кисәләр икән, шулар тотканнар... *(Киенеп бетә, ачы, каһәрле тавыш белән).* Ярар, кыйлансыннар әле, мин алардан бергә унны түләтермен... *(Чыгып китә).*

Г ө л җ а м а л *(куркып елый башлаган балаларын җитәкли дә чыгып йөгерә).* Ходаем, тагы ниләр генә күрәсебез бар икән?!

Ф ә т х и я *(ялгыз кала. Яңадан Камәрнең әйберләре янына бара).* Әй, бала, бала! Нәрсәләре дә чишелмәгән бит бичаракайның!.. Иртәгә әнкәсе янына бармакчы иде... Анасын да күрә алмый калды, мәрхүмкәй!

Т ә р ә з ә д ә н т а в ы ш . Тегеләрне китердек, кая илтик?

Ф ә т х и я *(коты очып, катып кала).* Ходаем, бу нихәл инде бу? *(Бөтен бу вакыйга буенча сүзсез, караватт буенда хәйран булып тора).*

Т и м е р к ә й *(ишектән атылып килеп керә. Тәрәзәгә барып каты тавыш белән кычкыра).* Монда китерегез собакаларны!

Үзе йөгереп ишеккә бара; чыгам дигәндә, б и ш - а л т ы я р л ы к р ә с т и ә н кыйнап, суккалап, акыртып ике ү т е р ү ч е н е төрткәләп кертәләр. Аларны күрүгә Тимеркәй бераз кире чигенә, каһәр белән карый.

Ү т е р ү ч е л ә р *(авылча яхшы киемдәләр, кыйналудан йөзләре шешенгән, күгәргән, куллары артка бәйләнгән. Тыштан ук елап кычкырып керәләр).* Алла!.. Алла!.. Үтерәләр... Тәүбә... Тәүбә...

Т и м е р к ә й *(йөзләренә бер генә карый да ике кулы белән икесенең җилкәсеннән алып, ике якка бәрә).* Сезме үтерүчеләр? Сезме революционерларның канын эчүчеләр? Хәзер тәүбәме? Хәзер алла искә төштеме?

Җ а м а л и *(аның артыннан башка крәстиәннәр кызып кыйный башлыйлар).* Ныграк бир каһәрләргә! Җәһәннәмгә җибәр үзләрен! *(Ашыгып, Батырхан килеп керә).*

Б а т ы р х а н *(мондагы кыйнашны күрүгә кинәт бусагада туктый, аның башы һәммәнең өстеннән күренә. Коточкыч тавыш белән кычкырып җибәрә).* Бу ни эш бу? Сез ни эшлисез?

Һәммә кеше кинәт туктый. Тын була. Тимеркәй, үзенең эшенең бик артык хаклы икәнлегенә ышанган кыяфәт белән бөеренә таяна төшеп, идән

уртасына баскан хәлдә, Батырханга карап тора. Үтерүчеләр дәшми-тынмый аска карап катып калалар.

Батырхан *(йөрәк яргыч каты, каһәрле тавыш белән үтерүчеләргә).* Сезме Камәр иптәшнең палачлары?!

Тимеркәй *(ачулы шелтә белән Батырханга).* Нигә тагын юкны сорашып торасың инде? *(Крәстиәннәрнең башлыгы Җамалига, тагын бер яшьрәк егеткә күрсәтә).* Әнә алар бит өсләренә барып чыкканнар! Җамали абзый, Сәлим иптәш! Сез нәрсә тагы авызыгызга су капкан кебек дәшми торасыз?

Батырхан *(Җамали белән Сәлимгә),* Җамали абзый, Сәлим туган, дөресен сөйләгез! Үз күзегез белән күрдегезме?

Җамали *(кулындагы күн бияләйләрен билбавына тыга-тыга).* Иманлы авыз белән ялган сөйләп тормам инде! Алар безгә икешәр мең сум акча бирергә дә әйттеләр, без алмадык.

Батырхан *(идән уртасынарак урындык куя да утыра. Башкалар элекке хәлләрендә калалар).* Син иплэп сөйлә: кайда, ничек булды?

Ишектән Насыйб белән Ярми килеп керәләр дә сүзсез туктыйлар. Берничә хатын-кыз, бала-чага керә.

Җамали. Менә бу иптәшләр белән *(крәстиәннәргә күрсәтә)* теге аклар җимереп киткән күперне төзәтер өчен таш чыгара идек... Бетереп кайтыйк ди торгач, соңгарак калганбыз. Караңгы төшкән иде инде. Кайтырга дип чыксак, түбәннән, чокырдан әллә нинди бер йөрәк яргыч тавыш килә башлады. Йөрәкләребез «шу» итеп китте. Мөгаен, берәрсен үтерәләр дип, шул якка йөгердек. Анда чаптык – юк. Монда чаптык – юк. *(Сәлимгә күрсәтә).* Шуннан соң менә Сәлим туган: «Монда, монда! Мөгаллимә апаны үтереп ташлаганнар!» – дип кычкырып җибәрде. Ул арада... менә Галиләр *(икенче крәстиәнгә күрсәтә)* «Үтерүчеләр монда, монда!» – дип кычкыра башладылар... Барсак *(үтерүчеләргә күрсәтә),* боларны безнекеләр тотканнар. Кыйнап, кул-аякларын бәйләп маташалар... Җан түзмәде, бераз биргәләп тә алдык...

Батырхан *(Тимеркәйгә бераз борчулы тавыш белән).* Ник һаман Камәр иптәшне алып кайтып җитмиләр инде?!

Тимеркәй *(әрнеп, ашыгып).* Кайталар, хәзер кайтып җитәләр. Таш күперне аклар бозып киткән. Аннан ат белән чыгарлык түгел. Боларны *(үтерүчеләргә күрсәтә)* басмадан чыгардылар... Мөгаллимә апаны тегермән бөясе аша алып кайталар.

Батырхан *(аякка калка; һәммә кеше тына, аңа карыйлар, бераз сүзсез торганнан соң).* Әйтегез, сезме Камәр иптәшнең палачлары?!

Үтерүчеләр *(дәшми-тынмый, һичкемгә күтәрелеп карамыйча,*

*Батырханның аягына егылалар. Шашып, елап, кызганыч тавыш белән).* Без белмәдек, безне котырттылар... һәммә явызлыкның башы шул кәнтәй марҗада, диделәр... Безне кичер, Батырхан абзый!

Батырхан *(бөтен гәүдәсе белән катып, тимерләнеп, үтерүчеләргә югарыдан карый, рәхимсез тавыш белән).* Торыгыз! Кеше котырыгына карарга сез балалармыни? *(Насыйб белән Ярмигә).* Алыгыз боларны.

Насыйб, Ярми *(берьюлы).* Кая илтик?

Батырхан *(шелтә белән).* Эшче-крәстиән палачларын кая илтәләр диме? Духонин штабына [22+], Могилёв губернасына!

Тимеркәй. Аңламасагыз, үзем әйтәм: җәһәннәмгә! Үзләренең дуслары янына!

Насыйб, Ярми, крәстиәннәр белән бергә, үтерүчеләрне алып чыгып китәләр. Алар артыннан Тимеркәй дә чыга. Ләкин тәрәзәдән тавыш килгәч, ишек бусагасыннан кире борылып, тәрәзәгә таба бара.

Кәрим *(авыл советы рәисе, тәрәзәдән кычкыра).* Батырхан иптәш өйдәме?

Батырхан *(баядан бирле катып, хәйран булып торган Фәтхия карчыкка).* Әнкәй, син теге өйгә, Зәйния янына чыгып тор! Монда эш белән килгән кешеләр бар. *(Тәрәзәгә.)* Кем бар анда?

Кәрим *(тәрәзәдән).* Мин совет прсидәтеле Кәрим... Сезгә баягы кешене китердек.

Батырхан. Кертегез!

Кәрим белән ике кызылармеец Әхтәм Банаевны алып керәләр.

Кәрим. Без баядан бирле сезне эзлибез! Менә теге бәндәне тотып китерделәр.

Батырхан *(Банаевны баштанаяк карап чыга. Истиһза белән елмая).* Ә, иске таныш, господин Банаев!

Солдатларның берсе *(бер Батырханга, бер Банаевка карап томлыга-томлыга).* Командир иптәш, менә бу теге вакытта мөселманнарны чехка ант иттергән кеше...

Батырхан *(көлеп).* Беләм, иптәш, беләм... Без аның белән бик күңелле җыелышта булдык! *(Банаевка).* Хәтерегездәдер бит ул күңелле җыелыш?

Кәрим. Олаулар җыясы бар. Хәзергә сау бул, Батырхан. *(Чыгып китә).*

Банаев. Мәгаттәәссеф[1], хәтеремдә, Батырхан әфәнде...

Батырхан. Соң сез ничек үзегез дусларыгыз белән Себергә Колчак[23+] артыннан китә алмый калдыгыз?!

---

[1] *Мәгаттәәссеф* – кызганычка каршы.

Әхтәм Банаев. Ялгышасыз, әфәндем... Себергә минем элекке дусларым, хәзерге дошманнарым китте...

Батырхан. Алаймы? Соң теге вакытта чехларга ант итүче кем иде?

Тимеркәй *(баядан бирле ачуланып торган җиреннән кинәт кузгалып, револьверын тартып ала да Банаевка таба ташлана).* Нәрсәгә тагы юкны сорап торырга инде?! *(Атарга омтыла).*

Батырхан *(ике арага кереп, Тимеркәйнең кулларыннан тота, туктата, каты шелтәле тавыш белән).* Тимерхан, мин сиңа ничә рәт әйттем, башбаштаклык кылма дип!

Тимеркәй *(әрнү катыш каһәрле тавыш белән).* Син теге вакытта да, ялган сүзенә карап, Бәдри мулланы җибәрдең. Әнә ул хәзер Себердә Колчак өчен «Мөхәммәд өммәте» дигән полк төзергә ярдәм итеп йөри, ди. Бар бит попларның Иисус Христос полклары, безнекеләр дә шуның кебекне ясыйлар, ди. Бусы да шулай булыр...

Батырхан *(тыныч, ләкин кискен тавыш белән).* Беләм мин ни эшләргә кирәген. Сиңа әйтәм, хәзергә чыгып тор: син үзеңә үзең баш була алмыйсың!

Тимеркәй *(ачулы куркыту белән).* Мин сине, барыбер ячейка судына бирәчәкмен. *(Кызулап чыгып китә).*

Батырхан *(Банаевка).* Сез үзегезнең чехларга ант итүегезне яшермисез алайса?

Банаев *(тәүбәсен укыган мәхкүм тавышы белән).* Яшермим: ул вакыт мин чехлар яклы идем... Ләкин, әфәндем, аннан бирле күп сулар акты... Чехның, Колчакның йөзе ачылды...

Батырхан *(көлеп).* Йөзе ачылдымы? Әллә көчләре беттеме?

Банаев. Йөзе ачылды, мәсләкләре мәгълүм булды, әфәндем... Алар эченнән рус бае килеп чыкты... Шуның нәтиҗәсендә безнең фикерләремездә тирән үзгәреш – зур перелом булды. Мин хәзер советчы, бөтен иманым белән советчы! Безнең милли азатлыкларымызга Советтан башка юл юклыгы безгә кояш кебек ачык мәгълүм булды... Без хәзер...

Батырхан *(бераз елмаеп, кашын җыерып, Банаевның сүзен бүлә).* Ярый, ярый. Сез моннан соң Советка каршы бармаска сүз бирәсезме? Телем, сүзем, каләмем, эшем белән һичбер вакытта да, һичбер урында һичбер төрле каршылык кылмам дип вәгъдә итә аласызмы? *(Тәхкыйрле истиһза беләк елмая, читкә борыла).*

Банаев. Итәм, мең мәртәбә ант итәм...

Батырхан *(тагы ныграк истиһза белән елмаеп).* Әллә шуны язып та бирәсезме?

Банаев *(күкрәк кесәсеннән каләм, кәгазь чыгара башлый).* Язам,

язам... Советка ант итеп язам...

Тимеркәй *(тәрәзәдән кычкыра).* Батырхан иптәш, дивизия штабыннан приказ китергәннәр. Сине сорыйлар. Тиз генә монда чык!

Батырхан *(аягүрә язып маташкан Банаевка өстәл, урындык күрсәтә).* Утырып торыгыз. *(Кызуланып чыгып китә).*

Банаев бер язып ерта да тагы башлый. Язганын укып карый, югарыда Батырхан әйткән сүзләрне тәкрарлый: «Телем, сүзем...» Батырхан, аның артыннан Зәйния килеп керәләр. Батырханның кулында пакет. Зәйния нидер сизенгән кебек куркып агарынган.

Батырхан *(ашыгыч хәлдә пакетны ерта, тиз-тиз күз йөртә. Зәйнияне бер читкә алып, яшерен сер рәвешендә әйтә).* Дивизия штабыннан хәбәр килде. Минем полк бүген таңда выступать итәргә тиеш! Тиз генә юл кирәкләрен әзерлә, без хәзер китәбез.

Зәйния *(кинәт башын тота).* Син бит безнең полк ун көн отдыхта дигән идең... Бер атна монда тормакчы идең... Бу тагы нинди ашыгыч китү инде?!

Батырхан. Шулай инде!.. Шулай дигән идем... Ә менә хәзер приказ килде, сөйләргә урын юк, аңлыйсыңмы?

Зәйния *(кинәт бер карарга килә, кискен тавыш белән).* Алайса мин дә синең белән китәм. Күңелем суынды минем бу җирләрдән: мин монда бер үзем кала алмыйм!

Батырхан *(Зәйниянең күзләренә текәлеп).* Син анда нишләрсең?

Зәйния *(уйланып, газапланып).* Ни эшлим? Мин монда калсам, акылымнан язармын... Мине калдырма! *(Иренә сыена, иркәләнеп кулыннан ала).* Син әле дә җиде-сигез ел ялгыз йөрисең! Мин анда сине тәрбияләрмен, сиңа матур, уңай тормыш төзермен... Аннан соң, аннан соң авыру солдатларны карармын!.. Ярыймы, бәгырем, алып барасың бит?!

Батырхан *(аз гына вакыт Зәйниянең күзенә сүзсез карап тора, карарга килеп кулын кыса).* Ярый. Алайса тиз әзерлән!

Зәйния. Менә нинди көтмәгән бәхет! *(Җиңел, шат атлап чыгып китә).* Без хәзер китәбезме?

Батырхан. Хәзер, хәзер китәбез! Тиз бул!

Тышта бик якыннан рәттән өч мәртәбә мылтык аткан тавыш килә.

Батырхан (*тәрәзәгә ташлана, каты кычкырып җибәрә, Банаев куркуыннан сикереп тора да тагын утыра).* Бу ни эш? Кем шаяра анда?

Кулына револьвер тотып Тимеркәй, аның артыннан ук трубкасы белән Әптерәш карт килеп керә.

Батырхан. Бу кем эше? Кем шаяра анда?

Тимеркәй *(агарынган, ләкин кискен тавыш белән).* Һичкем

шаярмый! Мин Вәли абзыйны атып үтердем!

Батырхан *(кызу атлап, аның алдына килә, күзләренә текәлә, каты тавыш белән, ләкин ашыкмыйча).* Кем кушты сиңа очраган бер кешегә атып йөрергә? Бу нинди башбаштаклык! Китер монда! *(Револьверын ала да караватка ташлый).*

Тимеркәй. Теләсәң ни эшләт: мин барына да риза! Ул явыз кулак әллә кем белән сөйләшеп бара: теге карт иблис Шәйбәкне дөмектергәннәр иде, ди... Ярый, ару булган, инде куштан Камәрне дә җәһәннәмгә озатканнар икән, ди. Ишеткәч, түзмәдем... үземне-үзем белмичә аттым...

Әптерәш. Акылың бармы? Ул бит синең агаң! Ул синең атаңның туган энесе бит!

Тимеркәй *(кызып, ачуланып, кул селкә).* Агайны гына түгел, андый урында туган атайны да кызганмам мин!

Әптерәш. Ут белән уйныйсыз, балалар, Алла үзе сакласын! *(Трубкасы белән мич алдына бара. Кабызып, морҗага тарта башлый).*

Батырхан. Агаңмы, атаңмы – эш анда түгел! Син моннан соң болай башбаштакланма! *(Тимеркәйне бер читкә ала. Яшерен рәвештә).* Штабтан приказ бар, Колчак безнең Ялантау фронтын өзгән. Минем полк бүген таңда выступать итәргә тиеш. Без хәзер китәбез. Бар, әзерлән! Насыйб белән Ярмигә дә хәбәр ит. *(Әптерәшкә).* Бабай, син шул хәзер генә үтерелгән Вәлинең гәүдәсен каравыл йортына илтеп ташла! Берүк Зәйниягә күрсәтмә! Без хәзер китәбез. *(Әптерәш, Тимеркәй чыгып китәләр. Батырхан Банаевка таба килә).* Безнең эшләр бик тыгызланып китте... Кая, бетердегезме?

Банаев *(каушап, калтырабрак кәгазьне бирә).* Шулай ярармы икән?

Батырхан *(кәгазьне укымый, карамый, җирәнгәнсыман бер читтән генә элеп ала да тәрәзә төбенә ташлый).* Ярый, ярый... Барыгыз... Сезнең кебек халык бик койрыксыз булып чыкты! Алар диңгезгә ташланган йомычка кебекләр: әле Дутов, әле чех, әле Колчак, әле Совет ягына чыгып чайкалалар... Мин сезне сынау өчен чыгарам... Аз гына, аз гына бер эшегез сизелсә, хөкемсез-нисез үз кулым белән атармын мин сезне!.. Барыгыз!..

Банаев. Рәхмәт сезгә! Бик рәхмәт, Батырхан иптәш... Әфәндем, миннән Советка хыянәт булмас... Мин Советка тугры, иманлы хезмәтче булырмын. *(Башын ия, чыгып китә).*

Батырхан. Менә кызганыч бәндәләр!

Насыйб, *Ярми (бергә кайтып керәләр).* Тегеләрне озаттык.

Батырхан. Штабтан приказ килде. Без хәзер китәбез. Бар, әзерләнегез!

Тимеркәй *(килеп керә, Батырханга).* Мин дүрт олау китерергә әйттем. Шул җитәрме?

Батырхан *(шелтә белән).* Андый эшне миннән сорама, үзең бел, үзең эшлә!

Җамали *(аның белән биш-алты ярлы крәстиән керә).* Батырхан туган, син китәсең дип ишеттек. Шуңа күрә ашыгып яңадан килдек. Шәйбәк бабайны үтерделәр... Шәнгәрәйне, тимерче Габдулланы үтерделәр... Мөгаллимә Камәрне дә үтерделәр... Шул үтерүгә катнашканнарның күбе якты дөньяда рәхәтләнеп йөриләр... Менә безне дә чех вакытында «бәлшәүникләр спискасына» кертеп язып биргәннәр... Аларга бернәрсә дә булмый калырмыни шулай? Сез киткәч, кем карар?

Батырхан *(крәстиәннәргә).* Ярар, әйтүегезгә бик рәхмәт! Барын да карарбыз. *(Тимеркәйгә).* Тимерхан туган, син монда иртәгәчә кал: мәрхүм Камәр иптәшне кадерләп, олылап күмәрсез... Менә бу иптәшләр әйткән эшне дә карарсың!

Тимеркәй. Булмас, җизни, булмас. Мине беләсең: ул эшләрне тикшерә башласам, мин йә һәммәсен кырып бетерермен. Андый вакытта минем йөрәк түзми: монда калмыйм, мин синең белән сугышка китәм... *(Насыйбка күрсәтә).* Менә Насыйб иптәш калсын, ул сабыр кеше, иплəп карар, тикшерер.

Батырхан *(җиңелчә елмая, Тимеркәйнең кулын кыса).* Тимерхан туган, син хәзер үзеңне бик яхшы аңлый башладың. Вакыт-вакыт бик артык кызып китүләрең өчен мин сине гаепләмим.

Тимеркәй. Их, җизни, белсәң иде минем йөрәкнең әрнүен! Мин гомерем барынча җәбер, җәфа күрдем. Шулар йөрәккә кан булып каткан... *(Санап әйтә).* Куркам мин, жизни, аларны кырып бетермәсәм, яңадан баш күтәрәләр дә безне тагын элекке кебек кол итәләр дип куркам...

Батырхан *(кискен каты тавыш белән).* Курыкма, туган, курыкма! Безне үтерсәләр, урынына мең туар. Ул каннар әрәм китмәс! Аңлыйсыңмы? Ышанасыңмы?

Тимеркәй *(дәртләнеп, гайрәтләнеп).* Ышанам, мең кат ышанам!

Батырхан *(кинәт борыла, бөтенләй гади тавыш белән Насыйбка).* Насыйб иптәш, алайса син иртәгә чаклы монда калырсың, тикшер, гаеплеләрне яп. Ләкин атма! Хөкем ахырдан булыр. *(Тимеркәйгә).* Безгә китәргә вакыт бик җитте; ник һаман Камәр иптәшне алып кайтмыйлар инде?

Насыйб. Ярый. Аңладым. Председатель белән бергә эшләрбез бит.

Батырхан. Әлбәттә, бергә, һәммә эшеңне халык белән киңәшеп эшлә.

Тәрәзәдән беренче тавыш. Олаулар килде. Шунда көтәргәме?

Тимеркәй *(тәрәзәдән башын чыгара).* Шунда көтсеннәр! Арбаларында салам бармы, булмаса, салсыннар!

Тәрәзәдән икенче тавыш *(ат туктаганы, арба шыкырдаганы,*

*«ту-у... ту-у...» дигән тавыш ишетелә. Берничә авыздан).* Ипләп, ипләп! Менә бу яктан!

Батырхан *(акрын эчке тавыш белән).* Камәр иптәшне алып кайттылар бугай... *(Ашыгыч чыгып китә).*

Тимеркәй (эчке кайгылы тавыш белән). Ах, ничек мин аны үлек хәлендә күрим! *(Батырхан артыннан ук чыга, аңа Насыйб, Ярми дә иярә).*

Батырхан *(тавышы ачык ишектән килә).* Урам як өйгә! Туры, туры! Уңгарак!

Камәрнең гәүдәсен алдан Батырхан белән Тимеркәй, арттан Җамали, Кәрим, Әптерәш, Насыйб, Ярми, Гөлҗамал, Фәтхия карчык, баягы крәстиәннәрнең һәммәсе, унлап кызылармееуц озын бер тактаны күтәреп кертәләр; аның өстендә мөгаллимә Камәрнең үле гәүдәсе; күз, каш, борын җимерек; бөтен йөз шешеп, яраланып беткән, чәче тузылган, яулыгы шуны бераз гына җыйган, ләкин каплый алмый. Дәшми-тынмый үлекне идән уртасына китереп куялар.

Фәтхия карчык *(үлеккә иелә төшеп карый).* Изге җаннардан иде, мәрхүмкәем... Аллаһ тәгалә урынын җәннәттә кылсын... *(Кул күтәреп дога кыла. Батырхан белән Тимеркәйдән башкалар кул күтәреп дога кылалар).*

Зәйния *(өйгә тулган халыкны ерып, таптап, шашып килеп керә. Үлекне күрүгә, үз-үзен белмичә, ачы кызганыч аваз белән елап, Камәрнең гәүдәсенә ташлана).* Җаным, бәгырем!.. Камәркәем, сине дә бетерделәрмени?!

Батырхан *(тиз үк килеп, Зәйнияне кочаклап күтәреп ала. Авыр, кайгылы тавыш белән).* Елама, Зәйния, бу корбаннар әрәм булмас!

Зәйния *(карышмый, иренең кул астына кергән хәлдә акрын гына елый-елый сөйләнә).* Ул нинди матур уйлар белән кайткан иде... Эшлим, ди иде... Бу газаплы тормыш бетәр, дуслык, матурлык белән тулы көннәр килер, ди иде. *(Насыйб башлагач, аңа аптырап карый да сүздән туктый).*

Насыйб *(ни әйтәчәген үзе ачык белмәгән рәвештә, халыкка карап ачулы, каһәрле тавыш белән сүз башлый).* Менә... менә, агайлар, күрәсез бит... Ул бит... беренче адәм иде... Аны да бетерделәр бит... Шулай булгач, без ничек рәхимле булыйк...

Җамали *(аның артыннан башка крәстиәннәр кузгала башлыйлар, нидер әйтергә теләгән кебек кыланалар).* Батырхан туган... Менә бит, безне дә чехлар вакытында бәлшәүник спискәсенә кертеп аттырырга йөрделәр. Без дә үлемнән калдык.

Тимеркәй. Их, агайлар... Белсәгез, эшче-крәстиән халкыннан бирелгән корбаннарның санын! Шуңа күрә дә йөрәк түзми бит! Менә шуңа күрә дә... *(Нидер сөйләргә теләгән кебек алга чыга башлый).*

Батырхан *(ишарә белән Тимеркәйне туктата, башта сабыр, аннан соң ачулы тавыш белән халыкка карап сөйли, бөтен өй тын була).* Камәр иптәш эшче-крәстиән йөрәгеннән чыккан бер каһарман иде. Аны югалту – безнең өчен бик артык авыр. Ләкин, иптәшләр, өметсезләнергә урын юк. Безнең арадан берәүне алсалар, аның урынына мең туачак... Меңнәрчә Камәрләрнең, йөз меңнәрчә Шәйбәк, Шәнгәрәй, тимерче Габдуллаларның һәрбер тамчы каныннан меңнәр каһарман ярала... Буржуазия үзенең капиталын, җир-суын саклар өчен ниләр генә эшләмәсен, ахыр барып, һаман да без җиңәчәкбез! Бөтен дөнья контрреволюциясе, башы өзелгән аждаһа кебек, пролетариат кылычы астында өзгәләнәчәк! Миллионнарча шәһитләр канына манчылган кызыл байрак каршында бөтен дөньяны тез чүктерәчәкбез! Иртәгә кояшның чыгуына ышанган кебек, моңа да ышаныгыз, иптәшләр!

Башкалар *(һәммәсе берьюлы).* Ышанабыз... Ышанабыз... Мең тапкыр ышанабыз...

Батырхан. Озаклап матур сүзләр сөйләү – безнең эш түгел! Тиз әзерләнегез. Китәбез, иптәшләр! *(Батырхан киенә, җыена, коралларын, хариталарын рәтли башлый; башкалар таралалар, Зәйния дә чыгып китә).*

Зәйния *(бик тиз арада юлча киенеп керә. Кулында төенчек, ашыгып киенгән, җыенган Батырханга килә).* Менә мин әзер!

Батырхан *(киенүен дәвам иттергән хәлдә).* Зәйния, син яхшы уйладыңмы? Безнең белән китү кан эченә барып керү икәнен аңлыйсыңмы?

Зәйния *(кискен, нык).* Уйладым, аңлыйм! Синең белән бергә булгач, мин ут эченә дә шатлык белән барып керәчәкмен!

Батырхан *(Зәйниянең кулын кыса).* Ярый, аңласаң, ярый. *(Фәтхия әби белән күрешә.)* Әнкәй, исән бул хәзергә!

Фәтхия *(елап, күз яшьләрен сөртә).* Балалар, атагыз Себердә... Аңардан һичбер хәбәр юк... Кайтуыгызга шатланып җитә алмадык... Инде сез дә китәсез!.. Ходаем, бу нихәл бу? Без ничек түзик!

Зәйния. Елама, әнкәй, елама: хәзер монда безнең үзебезнекеләр бит инде. Без хәзер сиңа хәбәр җибәрербез. Үзебез дә кайткаларбыз... *(Кочаклашып күрешә, үбешәләр. Зәйния Камәргә килә, йөзенә намазлык каплый, карап тора).*

Батырхан *(Насыйб белән Кәримгә).* Камәр иптәшне олылап күмүне сезгә тапшырам. *(Әптерәшкә).* Габдерәшит бабай, син дә ярдәм итәрсең.

Насыйб, Кәрим, Әптерәш *(берьюлы).* Ярар, ярар, Батырхан туган! Кулдан килгәнне эшләрбез.

Батырхан *(китүчеләргә).* Һәммәгез әзерме? *(Зәйния аңа тотына. Шул вакыт урамнан зур кәрван рәвешендә ат-арба үткәне ишетелә. Күп*

*тавыш белән «Интернационал»[24+] җырлап үтәләр).*

Батырхан *(кузгала, аның артыннан башкалар да).* Киттек, иптәшләр! Урамдагы «Интернационал»га кушылып җырлап чыгып китәләр. Өйдә карчык кына кала. Тиз үк Әптерәш карт керә. Җыр дәвам иткән вакытта мөгаллимәнең йөзен ачып, намазлыгын рәтли; җыр кинәт туктый.

Фәтхия *(баядан бирле хәйран булып тәрәзәдән карап тора. Җыр туктагач, тәрәзәгә караган хәлдә).* Ходаем, бар икән кодрәтең! Менә ничә атналар инде, көн үтәләр, төн үтәләр! Туплар! Кызыл әләмнәр! Илаһым, хуҗам, кайдан килә, кая бара бу бәндәләрең?!

Шул хәлдә акрын гына пәрдә төшә

**Яңа кешеләр**. 1920 ел ахырында Казанда язылган. «Шәрекъ ярлылары» (Уфа вилаять мөселман эшләре шәгъбәсе һәм Русия Коммунист (большевиклар) партиясенең вилаять комитеты янындагы Татар-башкорт секциясе органы) газетасы, мәсәлән, үзенең 1920 елгы 31 октябрь санында: «Яңа кешеләр» (Г. Ибраһимов әсәре). Яңа язылып беткән югарыдагы әсәрне түземсезлек белән көтәбез» дигән информация белдереп чыга.

Драма беренче тапкыр 1920 елда Октябрь революциясенең өч еллыгы уңае белән Казанда татар театрында Мохтар Мутин куелышында һәм бер үк вакытта Уфада сәхнәгә куела. Беренче тапкыр 1921 елда Казанда «Өмид» матбагасында "Галимҗан Ибраһимов" имзасы белән басылып чыккан. Драма исеме астында җәяләр эчендә "вакыйга 1918-1919 нчы елларда Идел-Урал туфрагында" дигән сүзләр бар. Әсәр тексты ахырында "1920, октябрь, Казан" диелгән. Пьеса алдында Галә Ходаяровның «"Яңа кешеләр" турында бер-ике сүз» исемле кереш мәкаләсе урнаштырылган. Әлеге мәкалә тексты томның "Кушымта"сында тәкъдим ителә. Бу басмада Бибизәйния исемле героиня Бибизәйнәб буларак бирелә. Шактый урында автор сүзләре киңәйтелгән хәлдә бирелгән.

Шулай ук «Г. Ибраһимов әсәрләре тулы җыелмасы»ның 1931 елда «Яңалиф» басмасында чыккан 5 нче томына кергән. Пьеса исеме астында: (1920 нче елда язылды, беренче басмасы Казанда 1921 нче елда чыкты) – диелгән. Монда да Галә Ходаяровның кереш мәкаләсе тәкъдим ителә. 1956-1957 елларда чыккан "Сайланма әсәрләр"енең икенче томына кертелгән.

Томга текст 1931 елгы басмадан алынды.

[1+] 1921 елгы басмада түбәндәге өзек:

Җәйге кич. Хәйри байның урам буена салынган яңа өе. Өй авылча бай, чибәр җыештырылган. Ишектән кергәч сул кулда бик яхшы агартылган мич, аның янында идәндә зур җиз ләгән, зурлы-кечеле ике җиз комган.Түр диварның сул почмагында аш, чәй савытлары белән тулы зур пыяла шкаф. Шкафның мичкә караган ягында, диварга буе белән зур киң карават, анда яңа тышлы түшәк, ястыклар, мендәрләр, өр-яңа чыбылдык, киҗеле[1] ашъяулык җәелгән өстәл, урындыклар, эскәмия, өсте корама[2] яулык белән капланган чобар[3] калайлы зур сандык. Тәрәзәләр пәрдәле, ишек, тәрәзә яңакларына кызыл башлы, киҗеле сөлгеләр эленгән. Түшәмгә зур лампа асылган, ләкин ул ягылмаган, мич буенда кечкенә лампа янып тора. Дивары сәгать, шамаил,

[1] *Киҗеле* – кулдан эшкәртелгән тупас ефәк җеп катнаштырып сугылган.
[2] *Корама* – төрле аерым кисәкләрдән торган.
[3] *Чобар* – чуар.

көзге, татарча календарь, шүрлектә ниндидер кантур дәфтәрләре.

Пәрдә ачылыр алдыннан кайдадыр, ләкин еракта түгел, гармун белән “Уел” көе уйналган тавыш килә. Кемдер матур, калын аваз белән аңа кушылып җырлый. Пәрдә күтәрелеп җиткәндә, җырның соңгы ике мисрагы[1] ачык ишетелә:

Ак Иделкәйләрне, ай кичәбез,
Шундан китә безнең юлыбыз.
Шушы китүләрдән кайта алмасак
Һәр барчаңыз бәхил булыңыз!

Пәрдә ачылып бик аз гына вакыт үткәч, нидер эзләнгән, ниндидер хыялга киткән төс белән авыр, салмак, атлап Бибизәйнәб килеп керә. Аның өстендә тәнен кысыбрак торган килешле карасу күлмәк, башында артык каерып бәйләнгән кызыл-көрән яулык, аягында каты табанлы сырлы читек. Ул аптыраганрак төс белән өйдәге әйберләргә күз йөртә, аның бөтен торышында ниндидер тирән уй белән борчылганлык сизелә. Зәйнәб урам як тәрәзәгә килеп, карар өчен пәрдәне ачыйм дигәндә генә кайдадыр еракта бик каты туп аталар.

Зәйнәб (*туп тавышына сискәнеп китә, башын кинәт тәрәзәдән тартып ала да, ят, эчке, бераз хыялый тавыш белән кычкырып җибәрә*)

[2+] *“Уел” көе* – татар халык җыры

*Әрәмәгә керсәм, үлән сирәк,*
*Сахраларга чыксам, җир җиләк;*
*Эчемдә генә минем утлар яна,*
*Ник җилкенә икән бу йөрәк?*

*Ай-һай гына диеп бер кычкырсам,*
*Яңгырыйдыр кыя ташлары;*
*Табылмаган дөнья малы өчен*
*Каңгырыйдыр егет башлары.*

*Арыслан ла киек, ай, алдырмас,*
*Каршысында биек тау булса;*
*Егет тә генә кеше һич кайгырмас,*
*Газиз башы аның сау булса.*

[3+] *Ленин* – ...биттән карагыз.

[4+] *чех сугышы* – 1918 елның май аенда Чех-словак корпусы советларга каршы кораллы сугыш ачканы күз алдында тотыла.

---

[1] *Мисрагы* – юлы.

[5+] *Герман сугышы* – ...биттән карагыз.

[6+] *Февраль революциясе* – Рәсәйдәге 1917 елгы Февраль революциясе.

[7+] *Октябрь килгәч...* – Рәсәйдә 1917 елның октябрендә башланган революция, тарихта гражданнар сугышы башлангычы буларак билгеле.

[8+] Краснов –...биттән карагыз.

[9+] Корнилов – ...биттән карагыз.

[10+] Дутов –...биттән карагыз.

[11+] *Нәмруд* - борынгы Бабил (Вавилония) хөкемдарларыннан берсенең исеме. Риваять буенча, Аллаһы белән көндәшлек итү ниятендә булган Нәмруд, Бабил манарасын күккә кадәр төзи алмагач, дүрт бөркет тоткан сандык эченә кереп, күккә таба оча һәм ук ата. Җәбраил фәрештә бөтен атылган укларны кире аның өстенә төшерә.

[12+] *Фиргавен* – Коръән персонажы, борынгы Мисыр патшасының исеме. Коръәндә явыз тиран, үз-үзен тәңреләштерүче, ислам диненә өндәргә килгән Муса пәйгамбәргә каршы көрәшә. Әдәби әсәрләрдә явыз, кансыз патша, шулай ук каты күңелле, усал кеше мәгънәсендә кулланыла. Алласызлык һәм тиранлыкның иң югары ноктасы буларак исәпләнә.

[13+] *Бәни Исраил* – Исраил балалары, еврейләр. Исраил – Ягъкуб пәйгамбәрнең исемнәреннән берсе, еврейләрнең төп бабаларының исеме. Коръән аятендә телгә алына. Борынгы семит телендә “Аллаһ колы” мәгънәсендә.

[14+] *Дүртөйле* - хәзерге Башкортстан республикасы Дүртөйле районы, административ үзәге Дүртөйле каласы.

[15+] 1921 елгы басмада алдагы җөмлә урынында түбәндәге өзек килә:

*...Урманнарга, тауларга тоташкан зур мәйданның авылга караган ягында бик искергән волость конторы. Сәхнәнең түрендә бер акка – бер акка сузылып авыл күренеше китә, анда мәчет күренә, тау белән болын уртасыннан борылып елга агышы күренә. Контор бинасы мәйданга йөзе белән тора. Аның ишек башында русча “Волость правлениесе” дип язылган бик иске кара тимер вывеска куелган. Ишектән түргә таба зур тәрәзә. Конторның сәхнә түренә таба ягыннан читән белән әйләндерелгән бакча, аның эчендә агачлар күренә.*

[16+] 1921 елгы басмада бу урында түбәндәге өзек килә:

*...Камәр артык җитди төстә. Батырхан өстәл тирәсенә халыкка истиһзалы елмаю белән карап ала да Камәргә, башка юлдашларына нидер әйтеп куя. Семенов бу тоткыннар эчендә. Алар белән булудан хурланганлыгы йөзенә, хәрәкәтенә чыгып тора. Ул болардан аерылып, үзен читкәрәк куярга тырыша, өзлексез өстәлгә карый, аларга барып нидер әйтергә хәзерләнгәнлеге сизелә.*

*Иванов белән Шакировның котлары очкан, йөзләрендә үлем куркынычы, бөтен тормышларында үлем дәһшәте.*

*Тоткыннарны әйләнеп алган солдатлар башлыгы Емельянов, өзлексез як-ягына карана, каравылга нидер ишарә ясый. Мәйдандагы халыкның тезелешендә шул хәл күренә – баераклар алда, өстәлгә якынрак торалар, аларның йөзендә, кузгалышында бер бәйрәм шатлыгы балкый, ярлылыр арттарак, "бу ни хәл бу" дигәндәй аптырабрак торалар. Бунда татар да, башкорт, чуаш, чирмеш дә бар. Арада Хәйри байның ялчысы – Әптерәш, Насыйб, Ярми дә күренә. Ул башын сузып, сузып карый да, янындагыларга нидер әйтә. Хәйринең углы Вәли – халыкның алгы сафында, бик кызуланып, тавышланып, һәрбер кузгалышка кушыла. Бер читтә хатын-кыз бар. Алар арасында җылап, шешенеп беткән Зәйнәб, ике баласын ияртекән Гөлҗамал, Фәтхия карчык күренә. Бер вакыт шат йөз белән Зөһрә дә килеп чыга, ләкин Хәйри тиз генә нидер әйтеп аны кайтарып йибәрә. Хәйри бай – мәйданның каһарманы. Ул бер урында тора алмый: әле өстәлдәгеләргә барып, колактан колакка нидер сөйләшеп ала, әле баскан йирләрендә чыдаша алмыйча, дулкынланып өстәлгә ишелеп килгән халыкны кире чигендерә, тәртип кертә, әле аңа, әле моңа барып, тоткыннарга күрсәтеп, нидер әйтешеп ала. Аның бөтен торышында зур бер бәйрәм рухы аңкый.*

[17+] *Казан Хәрби шурасы* – Бөтенроссия мөселманнары Хәрби Шурасы, мөселман гаскәриләренең югары сәяси оешмасы. Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең 1нче корылтае карары белән 1917 елның июлендә Казанда оештырыла. Хәрби округ, армия, флот һәм аерым гаскәри берәмлекләр вәкилләреннән һәм корылтайда билгеләнгән 12 бәйсез әгъзадан торган. Үзәге – Казанда урнаша, Петроградта һәм Милли Шура карамагында бүлекләре ачыла. Хәрби Шура әгъзалары татар халкының милли азатлык хәрәкәтендә актив катнашалар. РСФСР Милләтләр эше халык комиссариаты Декреты нигезендә 1918 елның 24 мартында Хәрби Шураның үзәк оешмасы бетерелә.

[18+] *Карамалы* – хәзерге Башкортстан республикасы составына керүче авыл исеме.

[19+] *Таштамак* - хәзерге Башкортстан республикасы Авыргазы районындагы авыл исеме.

[20+] 1921 елгы басмада түбәндәге өзек килә:

*Көзге, сәгать, асылмалы лампа, сандык юк. Шкаф буш, тәрәзә яңакларындагы сөлгеләр, караваттагы чыбылдык, мендәрдәр алынган. Элекке җиз ләгән комганнар урынында бер иске комган. Ишек төбендә, түрдә шкафта, караватларда гаскәри киемнәр, кораллар, диварда штаб басмасы хариталар эленгән. Түрдә элекке сандык урынында бер юл*

*чемоданы...*

21+ *"Әттәхият"* – намаз ахырында тезләнеп укый торган догаларның берсе.

22+ *Духонин штабы* – Н.Н. Духонин (1876 – 1917), рус хәрбие, генерал-лейтенант. Революция чорында большевикларга каршы фетнәләргә җитәкчелек итүчеләрнең берсе. 1917 елның сентябреннән А.Ф.Керенский җитәкчелегендәге штаб башлыгы. 1917 елның декабрендә Могилев шәһәрендә матрослар тарафыннан Духонин үтерелә. Текстта исә "Духонин штабына, Могилев губернасына!" дигән сүзләр "теге дөньяга" мәгънәсендә килә.

23+ *Колчак* - ...биттән карагыз.

24+ *"Интернационал"* – халыкара гимн.